**Төп төшенчәләр:** себер татарлары, себер бохаралылары, метрика язулары, Тубыл губернасы, Бохара волосте.

Тикшеренү «Метрические записи XIX – начала XX вв. о тобольских и тюменских бухарцах как историко-лингвистический источник» исемле 20-412-720008 р_а_Төмән өлкәсе фәнни проекты кысаларында РФТФ финанс ярдәме белән башкарылды.

## Кереш

Россия Федерациясе халыклары телләрен саклау һәм үстерү – дәүләтнең стратегик бурычларының берсе, чөнки хәзерге вакытта күп телләр юкка чыгу чигендә тора. ЮНЕСКО мәгълүматлары буенча Көнбатыш Себердә яшәүче төркиләрнең – себер татарларының теле дә шундый телләрнең берсе. Хәзерге вакытта лингвистика фәнендә себер татарларының сөйләм теленең диалекталь үзенчәлекләре

турында шактый тулы мәгълүмат тупланган. Шул ук вакытта архив фондларында саклана торган язма сөйләм истәлекләренең күп өлеше әлегә кадәр өйрәнелмәгән.

Тикшеренү объекты – Тубыл губернасы Тубыл өязенең XIX гасыр һәм XX гасыр башына караган кульязма метрика китаплары. Тикшеренүләрнең хронологик кысалары XIX гасырның 30 нчы елларыннан XX гасыр башына кадәр вакытны колачлый.

Метрика кенәгәләрендә Тубыл өязе юрталарында төрле этник төркемнәргә һәм төрле сословиеләргә караган халыклар – иске ясаклы татарлар, Идел буе татарлары (оброчные чувальщики), йомышлы татарлар, шулай ук Урта Азиядән күчеп килгән бохаралылар (сартлар) яшәве турында мәгълүматлар сакланган. Гарәп язулы кульязма текстларны уку, транслитерацияләү, рус теленә тәрҗемә итү һәм тарихи-лингвистик анализ ясау социаль-тарихи контексттагы проблемаларны (бохарадан килгәннәрнең саны һәм урнашуы, шәхси мәгълүматлар – исемнәре, туу вакыты һәм туу урыннары, ата-аналарның исемнәре һәм социаль хәлләре, никахлашу шартлары, вафат булу вакыты һәм күмелү урыннары) гына түгел, бәлки, лингвистик (XIX гасыр һәм XX гасыр башы язма сөйләменең стилистик үзенчәлекләре, графикасы, орфографик, лексик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләрен) җентекләп һәм комплекслы карарга мөмкинлек бирә.

Кульязмаларда теге яки бу кешенең кайсы этник төркемгә, сословиегә каравы турында мәгълүмат белән беррәттән, аның шөгыленең төре хакында да мәгълүматлар теркәлгән. Аларга *йомышлы, ясаклы, казак, асдавнуй казак* ‘отставкадагы казак’, указлы имам, зирагатьчы (игенче), хезмәтче, балыкчы, аңтучы ‘балыкчы, аучы’, сәүдәгәрче ‘сәүдәгәр’, осидлич иноротич ‘утрак тормыштагы чит милләт кешесе (оседлый инородец)’, *асдавнуй урәтник* ‘отставкадагы урядник’ керә. Бу мәгълүматлар губерниянең социаль үсешен тасвирлау өчен кыйммәтле чыганак булып тора. Моннан тыш, теге яки бу билге буенча затларның исемнәренә социолингвистик анализ кардәш булмаган халыклар арасындагы тел элемтәләре турында, шулай ук алынма сүзләрнең язма телдә җайлашу дәрәҗәсе турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Себердә Бохара мәдәниятенең күптәнге тарихы бар. Себер бохаралылары күп тапкырлар тарихи-этнографик тикшеренүләр объекты булганы бар. XVIII гасырдан башлап, этнографлар, аерым алганда, Г.Ф. Миллер (XVIII гасыр), Н.М. Ядринцев (XIX гасыр), аларның Себерне үзләштерүдәге роленә, сәүдә юлларын салу процессында катнашуына, көнчыгыш мәдәниятен Себер җирләренә кертүгә игътибар иткәннәр. Хәзерге вакытта тарихчылар һәм лингвистлар бохаралыларның килеп чыгышын, социаль статусын, мәдәниятен, көнкүрешен, дини гореф-гадәтләрен, аларның Себердә ислам таралышындагы ролен актив өйрәнәләр.

Урта Азиянең катлаулы тарихи үсеш юлы үткән күченүчеләренең мөһаҗирләренең варислары буларак, себер бохаралылары вакытлар узуга җирле халыклар белән ассимиляцияләшкәннәр, Себердә яшәүче төрки халыкның мәдәниятен формалаштыруга зур өлеш керткәннәр һәм себер татарларының этносы структурасында әһәмиятле этник компонентны тәшкил итәләр.

XIX гасыр – XX гасыр башы истәлекләре, шул исәптән метрика язулары, халык санын алу документлары, хезмәт язышуы, үтенечләр һәм җыемнар буенча документлар, юридик процедуралар буенча язмалар, указлар, протоколлар, рапортлар һәм башкалар себер бохаралылары җәмгыятенең икътисади, сәяси һәм мәдәни үсешен өйрәнүдә мөһим чыганак ролен үти. Әлеге документларда Көнбатыш Себердә яшәүче бохаралыларның социаль, эшкуарлык, шул исәптән сәүдә эшчәнлеге, тормыш тәэмин итү системасы һәм традицион мәдәнияте турында да кызыклы мәгълүматлар урын ала.

**Тикшеренү материаллары һәм методлары**

Хезмәтнең фәнни әһәмияте Себер татарларының XIX гасыр – XX гасыр башы язма мирасын саклауда, актуальләштерүдә һәм өйрәнүдә күренә. Кульязма чыганакларның җирле халык тормышындагы мөһим вакыйгаларны тасвирлаган тарихи контексты аеруча игътибарга лаек. Тикшеренү материаллары – XIX гасыр һәм XX гасыр башына караган һәм Тубыл, Уфа шәһәрләре архивларында сакланган иске татар телендәге кульязма метрика кенәгәләре.

Тикшеренүдә фәнни алымнар тасвирлау-аналитик һәм микъдари-статистик методларны, этимологик һәм лексикографик тасвирлау ысулларын, лингвокультурологик анализ кебек лингвистик ысуллар комплексын бәйләп алып барылды. Системалы-структур метод текстларны билгеле бер структурага ия булган берәмлекләр сыйфатында карарга мөмкинлек бирде.

**Фикер алышу**

Россия Федерациясенең архив фондларын өйрәнү күрсәткәнчә, Тубыл губернасындагы татар телендәге метрика кенәгәләре Тубыл (Тубыл шәһәрендәге Дәүләт архивы), Төмән (Төмән өлкәсенең Дәүләт архивы) һәм Уфа (Башкортстан Республикасының Милли архивы) шәһәрләре архивларында саклана.

Тубыл губернасының Тубыл шәһәре Дәүләт архивында сакланган архив фондларының басылып чыкмаган һәм тикшерелмәгән документлары тикшеренү эшебездә чыганак ролен үти. Әлеге архивта Тубыл губернасының төрле торак пунктларындагы 32 мәчетнең гомуми саны 489 санау берәмлеге булган фонды саклана. Архив фондындагы делоларның күләме төрле, хәтта 600 битлек кульъязма текстлар бар. Әлеге метрика кенәгәләре үз эчләренә 1830дан 1917 елга кадәрге чорны ала, һәм бохаралылар яшәгән түбәндәге юрталар буенча белешмәләр бар: Әремзән (Аремзянские) (архив шифры – Ф.И639), Пәек (Байгаринские) (Ф.И645), Татар Вагай (Вагайские) (Ф.И647), Агытпаш Вершинские (Агитские) (Ф.И511), Вершинские (Ф.И632), Кучайлан (Епанчинские) (Ф.И643), Юршак (Иртышские) (Ф.И644), Бәргәр (Исеневские) (Ф.И638), Остамак (Иштамакские) (Ф.И520), Кызылбай (Казылбаевские) (Ф.646), Комарау (Комаровские) (Ф.ИФ.641), Селәз (Кульмаметские) (649), Әшле (Лайминские) (Ф.И510), Сатылган (Медянские) (Ф.И640), Меткә (Митькинские) (Ф.И518), Сала (Салинские) (Ф.И650), Саусган (Саусканские) (Ф.И635), Сопра (Супринские) (Ф.И648), Тубылтора (Тоболтуринские) (Ф.И513), Күкрәнте (Чебургинские) (Ф.И514, Ф.И633).

Себердәге авылларда бохаралылар еш кына башка этник төркемнәр белән бергә урнашканнар. 1909 елгы статистик мәгълүматларга караганда, Тубыл һәм Төмән өязләрендә 44 һәм 11 авыл исәпләнә [Список населенных мест, 1912]. Мәсәлән, XIX гасырда Тубыл өязендә ясаклы һәм / яки йомышлы татарлар белән бергәләп, Урта Азиядән күчеп килүчеләр түбәндәге торак пунктларда яшәгәннәр: Убаул – Абаульские (Тлешевские), Ягор-аул – Абызовские, Канавыл – Араповские, Әремзән – Аремзянские, Әшле – Ашлыкские (Лайминские), Пәек – Байгаринские, Капкана – Балахлейские, Кулай-авыл – Будалинские, Тубысы – Бегишевские, Татар Вагай – Вагайские, Агытпаш – Вершинские (Агитские), Кучайлан – Епанчинские, Игәй – Игеевские (Мало-Саусканские), Юршак – Иртышатские, Бәргәр – Исеневские (Бергельские), Иштәк – Истятские, Ешаир – Ишаирские, Ишәй – Ишеевские, Остамак – Иштаманские, Кызылбай – Козылбаевские, Катымкуй – Катангуйские, Селәз – Кульмаметские, Меткә – Миткинские, Сатылган – Медянские, Янаул – Новые, Пушнаш – Пушнятские, Рәнцек – Ренченские, Сала – Салинские, Сабанчылар – Собачкинские, Саусган – Соусканские, Сузгун – Сузгунские, Сүкләм – Суклемские, Сопра – Супринские, Тарган – Тархановские, Таутаматские, Шулгун – Тачимовские, Тубылтора – Тоболтуринские, Үткәрмә – Уткарминские, Цумык – Черторойские, Күкрәнте – Чебургинские, Шалцы – Шальчинские, Шамшы – Шамшинские.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: 1911 елгы Эчке эшләр министрлыгы Земский бүлегенең архивы фондларындагы язмалар раслаганча, XX гасыр башында Тубыл өязенең Бохара волосте бетерелә: «Тубыл Губерна Идарәсенең Гомуми Оешмасы, Крестьян башлыкларының фикере белән ризалашып һәм Өяз Съезды тарафыннан проектлана торган чит милләтләрне (инородец) җирләргә урнаштыруга бәйле аларның Крестьяннары турындагы Гомуми Положениене кертүне кичектерү кирәк түгел дип табып, түбәндәгеләрне билгеләде: Тубыл өязенең инородецлар яшәгән сигез волостендагы хәзерге 1 нче һәм 2 нче крестьян участокларына алмашка әлеге волостьлардагы авыллардан һәм хәзер бетерелә торган Бохара волостенда хисапта торучы җирсез бохаралыларны да кертеп исәпләп, җиде волость төзергә: Кучайлан (Епанчинские), Пәек (Байгаринские) һәм Сопра (Супринские) юрталарында яшәүчеләрне – Вагай волостена, Тубылтора (Тоболтуринские), Күкрәнте (Чебургинские) юрталарында яшәүчеләрне – Тубылтора волостена, Кулай-авыл (Будалинские), Игәй (Игеевские), Сатылган (Медянские), Саусган (Соусканские), Ишәй (Ишеевские), Юршак (Иртышатские), Пушнаш (Пушнятские), Сузгун (Сузгунские) юрталарында һәм Тубыл шәһәрендә яшәүчеләрне – Тобольско-Городовой волостена, Капкана (Балахлейские) юртасында яшәүчеләрне – Иштәк волостена, Ешаир (Ишаирские), Рәнцек (Ренченские), Катымкуй (Катангуйские) юрталарында яшәүчеләрне – Карагай волостена, Меткә (Миткинские), Корманак (Курманакские), Агытпаш (Вершино-Агитские), Кучайлан – Епанчинские, Игәй – Игеевские (Мало-Саусканские), Юршак – Иртышатские, Бәргәр – Исеневские (Бергельские), Иштәк – Истятские,

Ешаир – Ишаирские, Ишәй – Ишеевские, Остамак – Иштаманские, Кызылбай – Козылбаевские, Катымкуй – Катангуйские, Селәз – Кульмаметские, юрталарында яшәүчеләрне – Тукуз волостена кертергә (тәрҗемә безнеке – авт.). – (Общее Присутствие Тобольскаго Губернскаго Управления, с своей стороны разделив соображение Крестьянских Начальников и признав не желательным откладывать проектируемое Уездным Съездом введение Общего Положения о Крестьянах у инородцев до поземельного устройства последних, определило: взамен ныне существующих в 1 и 2 крестьянских участков Тобольского уезда восьми инородческих волостей образовать из селений этих волостей семь волостей, причислив безземельных бухарцев, состоящих на причислении в ныне упраздняемой Бухарской волости к волостям: к Вагайской волости – проживающих в юртах; к Тоболтуринской волости – проживающих в юртах Тоболтуринских и Чубургинских; к Тобольско-Городовой, проживающих в юртах Будалинских, Игеевских, Медянских, Саусканских, Ишеевских, Иртышатских, Пушнятских, Сузгунских и в г. Тобольске; к Истятской волости – проживающих в юртах Балахлейских, к Карагайской волости – проживающих в юртах Ишаирских, Ренченских и Катангуйских; к Тукузской волости – проживающих в юртах Митькинских, Курманакских и в Вершино-Агитских)» [РГИА. Ф.1291, оп. 84, д. 225, 1911]. Әмма Урта Азиядән чыгучылар әлеге үзгәрешләргә каршы киләләр һәм моны административ-территориаль фактлар белән генә түгел, этник сәбәпләр белән дә дәлилиләр. Тубыл өязенең почетлы бохаралылары – Вагай юртасыннан Абдулла Хисаметдинов һәм Сатылган юртасыннан Сәлахетдин Шахалиев гаризасында: «...Без, бохаралылар, башка кабиләләрдән аермалы буларак, себер татарлары белән диннән башка бернинди уртаклыкларыбыз да юк дип өстибез... (тәрҗемә безнеке. – авт.) - (Добавляем, что мы, бухарцы, особое совсем от остальных племя, ничего общего кроме религии с татарами сибирскими природными инородцами не имеющие…)» [РГИА. Ф.1291, оп.84, д.120, 1911] – дип билгеләп үтелә.

**Нәтиҗәләр**

Бохаралылар үзләре генә яшәгән торак пунктлар сирәк булган. Тубыл шәһәреннән ерак түгел генә урнашкан Комарау һәм Коллар юрталары (авыллары) шундыйларга керә.

Комарау юрталарының мәчет кенәгәләре мисалында метрика текстларының төзелешен һәм эчтәлеген тикшереп карыйк. Әлеге документларда ике торак пункт – Комарау һәм Хан авыл халкы турында мәгълүматлар китерелә. Язмаларда, традиция буенча өч өлеш – 1) туган балалар, 2) никахлашканнар, аерылышканнар һәм 3) үлгән кешеләр теркәлә.

Туучылар турындагы текстларда яңа туган бала турында түбәндәге мәгълүматлар китерелә:

1) җенесе һәм исеме: *ируглан Сөйүҗбакый*, *кызуглан Бибизахирә*;

2) туу вакыты: *фивральнең 22 нче көнендә*, *августның 19 нчы көнендә*, *үктәбернең 9 нда*, *нуйәбернең 20 нче көнендә*, *нуйәбернең 10 нче йәүмендә*;

3) этисе турындагы мәгълүматлар: *атасы сарт Мөхәммәдшәриф*, *атасы бухарич Габделбакый*, *атасы казак Ибраһим*, *атасы осдовной казак Алим*, *атасы зирагатьчы Нийаз*;

4) әнисе турында мәгълүмат: *анасы Рузыйбану*, *анасы Аппак*, *анасы Шәһәрбану*;

5) туу урыны: *Тобол өйәзе Комарау карьясендә дугды*, *Тобол өйәзе Хан карьясендә дугды*.

*Ил, авыл, карья* лексемалары текстларда синонимнар буларак билгеләнә һәм авыл мәгънәсендә килә. Алар И. Гиганов сүзлегендә дә шул рәвешле теркәлгәннәр: аул ‘деревня’ [Гиганов, 121 б.], ил, авул ‘село’[Гиганов, 534 б.].

**Комарау юрталарында 1839 нчы елда дөньяга килгән балалар теркәлгән кенәгәнең бер бите**



Никахлар һәм аерылышулар теркәлгән битләрдә түбәндәге мәгълүматлар бар:

1) никахланышучылар турында белешмә: *Тобол губернасы шул өйәзе Комарау иленең сарт Кодаш Билал углының кызы Фатыйманы, 17 йәшендә, шул ук илнең сарт Әхмәди Мөхәммәдәмин углына, 19 йәшендә, никахландырылды; Тобол губернасы шул өйәзе Комарау иленең сарт Әбуталиб Шәриф углының кызы Бибиҗамалны, 46 йәшендә, шул ук өйәзнең Шанңун иленең сарт Рузый Мөхәммәдгомәр углына, 66 йәшендә, никахландырылды; Тобол губернасы шул өйәзе Хан иленүң казак Көчүк Мәмшан углынуң кызы Зәйнәбне, йегерме йәшендә, шул ук өйәзнүң Шәйәхмәт иленүң казак Туктабай Йосыф углына, йегерме биш йәшендә, никахландырылды; Тобол губернасы шулук өйәзе Хан иленүң казак Корбанбакый Туктабай углынуң кызы Бинакәйне, унсигез йәшендә, шул ук өйәзнүң Хан иленүң казак асдавнуй урәтник Алим Кырымшак углына, кырык өч йәшендә, никахландырылды; Тобол губернасы шул өйәзе Комарау иленүң бухарич Гыйдбакый Мирсәфәр углының кызы Маһифирүзәне, йегерме бер йәшендә, шул ук өйәзнең Комарау иленүң бухарич указной имамы Сөйүҗбакый Габделгазиз углына, утуз тукуз йәшендә, никахландырылды*;

2) вакыты: *гыйнварның 8 нче көнендә, майның 28 нче көнендә, ийүннең 20 нче көнендә, уктәбернең 5 нче көнендә*;

3) кәләш белән кияү ягыннан ышанычлы кешеләр: *кыз тарафындан атасы Нийазмөхәммәд Этбакмас углы вәли вәкил булды вә кийәү тарафындан атасы Йагкуб Рәҗәб углы вәли вәкил булды, зәүҗәйеннең ризалыкларының шаһидләре әүвәл Билал Солтанмөхәммәд углы әлимза кылдум, Сөйүҗ Мәмәдйар углы әлимза кылдум*; *кыз тарафындан анасының атасы Рәхмәтулла Мәмәтйар углы вәли вәкил булды вә кийәү тарафындан атасы берлә тугма карендәше Этбакмас Ибнейәмин углы вәли вәкил булды, зәүҗәйеннең ризалыкларының шаһидләре әүвәл Габделнәзир Моратбакый углы әлимза кылдум, Кодаш Билал углы әлимза кылдум*; *кыз тарафындан дугма карендәше сарт Кодаш Билал мәрхүм углы вәли вәкил булды вә кийәү тарафындан атасы Мәмәтрузый Мирсәфәр углы вәли вәкил булды зәүҗәйеннең ризалыкларының шаһидләре Корбанбакый Габделгазиз мәрхүм углы әлимза кылдум, Һавазбакый Этбакмас углы әлимза кылдум*;

4) кәләшнең әти-әнисенә кияү бирә торган акчаның (мәһәр) күләме: *мәһәр мөсаммә ике йөз сум, йөз ун сумны хазир бирүб, калганны мәзкурә Бибизөһрә Билал мәрхүм кызы сораган вакытда вирәчәк булуб, мән, кийәү булгучы Әбүсәгыйд Мәмәтрузый углы әлимза кылдум дугма карендәшем кызым Бибизөһрәнең ризалыгы илән мәзкур шартга мән вәли вәкил булгучы Ходаш Билал углы әлимза кылдум; мәһәр мөсаммә биш йөз сум хәзир дә бирүб, мән кийәү булгучы Мәмәтйар Йагкуб углы әлимза кылдум һәм мәзкур шартга кызым Зарифәнең ризалыгы илән мән вәли вәкил булгучы Нийазмөхәммәд Этбакмас углы әлимза кылдум; Мәһәр мөсаммә кырык сум, хәзир дә бирүб, мән кийәү булгучы Көчүк Багҗан углы әлимза кылдум һәм мәзкур шартга кыз карендәшем Рәхимәнүң ризалыгы илә мән вәли вәкил булгучы Илйас Әсәнак углы әлимза кылдум*;

5) никахлашучыларны теркәүче имамның исеме: *Тобол өйәзе Комарау иленең мәншүрле мәхәллә имамы Сөйүҗбакый Габделгазиз углы никах хөтбәсене укудукыма әлимза кылдым*.

**Комарау юрталарында 1838 нче елдагы никахлашулар теркәлгән кенәгәнең бер бите**



Аерылышулар турындагы текстларда шулай ук кызыклы мәгълүмат урын ала:

1) аерылышучыларның исемнәре: *Тобол губернасы шул өйәзе Хан иленүң Мөхәммәдкәрим Нийаз углы хатыны Рәхимә Җантимер кызына халегъ вакыйг улунды; Тобол губернасы вә шул Комарау иленүң сарт Дәүләтбакый Габдессәлам углы хатыны Хәбибҗамал Гыйдбакый кызына халегъ вакыйг улунды; Тобол губернасы шул өйәзе Комарау иленең сарт Нийазмөхәммәд Этбакмас углы хатыны Зарифә Ибраһим кызына талак вакыйг кылды; Тобол губернасы шул өйәзе Ишәй иленең асдавнуй казак Сөйүҗбакый мәрхүм кызы Бибишәрифәгә шул ук өйәзенең Хан иленең зирагатчы Мөхәммәдәмин Мөхәммәдкәрим углында никахда улан хатуны Бибишәрифәгә үз ихтыяры илән үзе теләб җәмигъ хокук никахны мәзкүр Бибишәрифә илән хазир гүаһлар хозурында һәр икүмез ризалашуб вә гүаһлар хозурында бер талак баин илән талак кылдум;*

2) аерылышу көне: *гыйнварның 12 нче көнендә; мартның 28 нче көнендә; синтәбернең 7 нче көне*;

3) аерылышуның сәбәбе турында: *Мөхәммәдкәрим Нийаз углы хатыны Рәхимәне иренең әмерене инкяр кылыб, әҗнәбиләрнең эвләренә чыгыб йөрдеге сәбәбле, хосусан мәхәббәте йуклыгындан халегъ вакыйг улунган; Дәүләтбакый Габдессәлам углы хатыны Хәбибҗамал иренең әмерене инкяр идүб, әҗнәбиләрнең эвләренә чыгыб йөрдеге сәбәбле, хосусан мәхәббәте йуклыгындан халегъ вакыйг улунган; Нийазмөхәммәд Этбакмас углы хатыны Зарифә иренең әмериләә инкяр кылуб әҗнәбиләрнең эвләренә чыкыб йөрөдөге сәбәбле вә мәхәббәтлеге йуклыгындан; кийәү булгучы Сөйүҗбакый Габделкәрим углы зәүҗәсе улан Фатыйма илән ма бәенләрендә мәхәббәт йуклыгындан вә әмеренә итагать кылмаслыгындан;*

4) аерылышу кем теләге белән булуы хакында*: һәр икүмез ризалашуб вә гүаһлар хозурында бер талак баин илән талак кылдум; бәйин зәүҗәйен мөнәфәрәт кушыб халегъ кылур халеген хазир мәзкурә хатуным Зарифә Ибраһим кызындан хазир алдым вә разый улдум вә ма бәенләр вә нәвә улан хокукларын мөстәхикъларына тәслим кылдурдук, гадел шаһидләр хозурында муафикъ шәргъ гакде халегъ берен кылуб нөсхә вирелде; талак ләфызы хозурында улан шаһидләр; хәлег ләфызы хозурында улан шаһидләр; мәзкур Сөйүҗбакый үз ризалыгы илән вә үзе теләб хазир гүаһлар хозурында мәзкурә Фатыйманы бер талак бәин илән талак вакыйг әйләде вә хатун улан Фатыйма мәзкур зәүҗенең бер талак бәин илән талак кылмаклыгыны кабул әйләде;*

5) шаһитлар турында: *талак ләфызы хозурында улан шаһидләр шул ук өйәзнең шул илнең Рузый Мәһди углы вә Корбанбакый Мәрәк углы вә Йыйанхуҗа Әбуталиб углы әлимза кылдум;Ләфыз талакны гүаһлар хозурында мәзкур зәүҗ үзе ризалыгы илән теләб телендән иҗра әйләде;вә мәзкурә Фатыйма Уразай кызының хат белмәзлеге өчен хәзер соравы илән мән Йагъкуб Илйасов кулум куйдум.*

6) аерылышуны теркәгән имам турында: *Тобол өйәзенең Комарау иленең Дәүләтбакый Габдессәлам углы хатуны Хәбибҗамалга хәлегъ вакыйг кылганны шул өйәзнең Комарау иленең мәхәллә имамы Сөйүҗбакый Габделгазиз углының тәфтиш вә тәхрире илә мәгълүм итдүгене; Тобол өйәзе Комарау иленең мәхәллә*

*имамы Җәләледдин Җәгъфәр углы хатыны Уразабикә Нәкыйб кызына талак кылгандин соң гадде рәҗуг кылмадугы аңлаб вә белеб вә тәфтиш вә тәхрир кылыб вә шул сәбәбләр илән мәзкүрә Җәләледдин Җәгъфәр углы мәзкурә хатуны Уразабикә Нәкыйб кызына талак кылдыгуны тәкидләндүрде;Тобол өйәзе Комарау иленең мәншүрле мәхәллә имамы шушы мәзкур Хан иленең зирагатчы Мөхәммәдәмин Мөхәммәдкәрим углы мәзкурә хатуны Бибишәрифә Сөйүҗбакый кызыны бер хәлегъ вакыйг кылганны шул өйәзнең Комарау иленең мәхәллә имамы Сөйүҗбакый Габделгазиз углының бер талак бәин илән талак кылдугында хазир булуб гүаһландум вә нөсхә вирүлде.*

**Комарау юрталарында 1841 нче елдагы аерылышу теркәлгән кенәгәнең бер бите**



Метрикә китапларында вафат булганнар теркәлгән текстларда үлгән кеше турында түбәндәге мәгълүматлар китерелә:

1) кайсы җенестән булуы һәм исеме: *ир Кыршак*, *кыз Гайшә*, *ир углан Мөхәммәдсалих*, *кыз углан Хәбибә*;

2) үлгән көне: *априлнең 7 нче көнендә*, *фивральнең 16 нчы көнендә*, *априлнең 9 нчы көнендә*, *ийүлнең 5 нче көнендә*, *үктәбернең 29 нчы көнендә*;

3) яше: *бер айда*, *икенче йәшендә*, *йитмеш йәшендә*, *сиксән йәшендә*, *түрт йәшендә*, *унбиш көндә*;

4) вафатының сәбәбе: *айагында шеш зәхмәте илән вафат улды, алт тәһәрәте кәтмәмәк зәхмәте илән вафат улды, астма зәхмәте илән вафат булды, бума зәхмәте илән вафат булды, җен зәхмәте илән вафат булды, йаман кутыр зәхмәте илән вафат улды, йаман шеш зәхмәте илән вафат булды, картлык зәхмәте илән вафат улды, күз тигмәк зәхмәте илән вафат булды, кызылча зәхмәте илән вафат булды, очок зәхмәте илән вафат булды, тамагына йаман шеш чыкмак зәхмәте илән вафат улды, углан зәхмәте илән вафат булды, углан кәтүрмәк зәхмәте илән вафат булды, чакма зәхмәте илән вафат булды, чахотка зәхмәте илән вафат булды, чәчәк зәхмәте илән вафат булды, эч шешмәк зәхмәте илән вафат улды, эч шешмәк вә күбмәк зәхмәте илән вафат булды*. Түбәндәге авыру исемнәре киң таралган: *астма* (استمه)/ *азумә зәхмәте* ‘бизгәк (лихорадка)’ (< греч. *asthma*); *бума* (بومه) *зәхмәте* ‘бума ютәл (коклюш)’; *кызылчә зәхмәте* (قزولجه زحمتی) ‘кызамык (корь)’ (досл. красная болезнь); *чәчәк* (ججک / ججاك) *зәхмәте* ‘чәчәк (оспа)’; *чикутка* (جیکوتکه) *зәхмәте* ‘чахотка’ (< рус. *чахотка*); *эч* (ایج) *зәхмәте* ‘эч авыруы, дизентерия’.

**Комарау юрталарында 1841 нче елдагы үлгәннәр теркәлгән кенәгәнең бер бите**



Әлеге метрика текстлары авыл җирлегендәге авырулар очракларын ачык чагылдыра. Графиктан күренгәнчә, авылларда бизгәк авыруы киң таралган, ул 1842-43 елларда иң

югары ноктага җиткән. Чахоткадан үлем очраклары графикта өзек булмаган диярлек сызык белән килә. XIX гасырның беренче яртысында бума ютәлдән үлүчеләрнең проценты югары. Чәчәк һәм дизентерия эпидемиясеннән үлүчеләр шулай ук күп булган. Балаларның кызамык белән авырып үлүләре эпизодик рәвештә характерлана.

Рәсем

**Халык арасында бизгәк, кызамык, бума ютәл, дизентерия, чахотка, чәчәк авыруларыннан үлүчеләр саны динамикада**




5) җирләнгән урыны: *Тубыл өязе Комарау карьясендә дәфен улынды, Тубыл өязе Хан карьясендә дәфен улынды* ‘*Тубыл өязе Хан авылында җирләнде*’.

Әйтергә кирәк, метрика язуларында тубыл һәм түбән бохаралыларына тау өчен вариатив берәмлекләр кулланыла: *сарт* // *сард*, *сартия* // *сардия* // *зәртия*, *бухарич*, *бухартин* // *бухардин*. Бер үк документта әлеге лексик берәмлекләр янәшә кулланылырга да мөмкин: 1851 елда, мәсәлән, Тубыл губернасының Түбән өязе Каскара (Каскаринские) юрталарында 1851 нче елда туган балаларны теркәгән битләрдә *атасы бухартин Әмин*, *атасы сартия Сәфәр* кебек мисалларны күрергә була.

Рус һәм Тубыл губернасы татарлары телендә язылган 1905 елгы «Русско-татарский разговор» хезмәтендә *сарт* сүзе теркәлгән: *сарт* ‘бухарец’: *Там есть и киргизы и бухарцы и татар и русские – Анта кыргыслар та, сартлар та, нугайлар та, урыслар та пар*; Чем торгуют бухарцы? – *Сартлар ни пелян саута кылаты*?; Бухарцы торгуют халатами и бязью – *Сартлар цапан, пюс пелян саута кылатылар* [Русско-татарский разговор, с. 88].

Комарау юрталарында халыкның төп өлешен бохаралылар тәшкил иткән, алар үзләрен «сарт» яки «бухарич» (кульязмалар буенча) дип атаганнар. Биредә алардан тыш, игенчеләр, ясаклы татарлар, казаклар гаиләләре белән яшәгән.

Яңа туган малайларның һәм кызларның әтиләрен этник чыгышы һәм сословиесе ягыннан караганда, түбәндәге төркемнәр аерылып чыга.

Таблица

Торак пунктлар буенча этник / сословие төркемнәренең процент нисбәте (%)

| **Яңа туган сабыйларның аталарының этник / сословие төркеме** | **Комарау авылы** | | **Хан авылы** | |
|---|---|---|---|---|
| | **малай-лар** | **кыз-лар** | **малай-лар** | **кыз-лар** |
| бохаралы | 31,7 | 32,4 | 1,7 | 1,3 |
| игенче | 0,8 | 0,4 | 10,2 | 8,7 |
| казак | 0,2 | 0,2 | 5,4 | 4,2 |
| даими шунда яши торган чит милләтләр | 0,2 | - | 0,6 | 0,2 |
| отставкадагы урядник | - | - | 0,4 | - |
| ясаклы татар | 0,2 | - | 0,6 | 0,6 |

Әлеге таблицалардан күренгәнчә, яңа туган балалар арасында бохаралылар күпчелекне (67,1%) тәшкил итә.

Әлеге этнонимнарның кулланылышын өйрәнү филология фәне өчен дә, тарих фәне өчен дә актуаль. Хәзерге себер татарларының фамилияләрендә бохара эзе очрый. Мәсәлән, безнең экспедиция вакытында Төмән өлкәсе Вагай районының Аусаҡ авылында (Агытпаш авылыннан 25 чакрым ераклыкта) 2016 елда җирле халык турында Бухарин Әхмәтшәрип Усуковичтан (1934 елда туган) язып алынган теркәлгән: «*Пы түң аусаҡлыҡ, ағачлыҡ пулған. Менә пы Аусаҡ тигән аwыл йөте частән тораты. Менә кәсер килсәгес Ҡартаwыл йаҡтан, менә мыннан сес усасыс сул йаҡҡырны, ул аталаты Шылғанлы, менә пер аwылтан, менә өсөләте ҡуй, саслар, аннан ул йаҡҡа тағын китсәгес, ул аталаты Азис ҡыр. <...> Алай Ҡартаwыл, Ҡартаwыл самай ул йуван ите, мынта унпер генә өйчегәч ите белүтә. Мының местнай кешесе пачти пөткән. Мынта килгәннәр, почуяли, что мынта питаться иткәле пулаты, туйынғалы пулаты, мынта менә местнайтан ҡалған Турышевлар, менә мин Бухарин, Ниязов, Абнасыровы, Мезралие-*

*вы, Чамалетдиновы. Тәк, Ныязов пелән Чамалетдиновы, Абуковы, менә фсё! Қалғаннары пөтөнөсө килгәннәр (Бу урын усаклык, агачлык булган. Менә бу Аусакдигән авыл җиде өлештән тора. Менә хәзер килсәгез Картавыл ягыннан, менә моннан сез узасыз сул як кырны, ул атала Шылганлы, менә бер авылдан, менә өзелә бит, сазлар, аннан шул якка тагын китсәгез, ул атала Азис кыры. <...> Алай Картавыл, Картавыл иң зур иде, монда унбер генә өй иде. Моның җирле кешесе беткән диярлек. Монда килгәннәр, почуяли, что монда тукланырга була, туйынырга була, монда менә местнайдан калган Турышевлар, менә мин Бухарин, Ниязов, Абнасыровлар, Мезралиевлар, Җамалетдиновлар. Тәк, Ниязов белән Җамалетдиновлар, Абуковлар, менә бетте! Калганнары бөтенесе килгәннәр)*». Респондентның сөйләмендәге фонетик үзенчәлекләр, төгәлрәге, ч-лаштыру үзенчәлегенә игътибар итик. Аусак авылында яшәүчеләрнең сөйләме тубыл һәм тевриз сөйләшләренең күчеш зонасына карый. Д.Г. Тумашева тевриз сөйләше турында яза: «Сөйләштә тартык авазларның төп үзенчәлеге – ч-лаштыру, ягъни диалекталь ц урынына гомумтөрки ч авазын куллану хас. Югары авылларда артикуляциясе буенча ч тартыгы татар телендәгечә – өрелмәле, ә түбәнге авылларда катнаш, ягъни өрелмәле ч һәм аффрикат ч әйтелә. *ц ~ ч ~ ш* чиратлашуы очрый» [Тумашева, 294 с.].

## Йомгак

Шулай итеп, татар телендәге метрика кенәгәләрен лингвокультурологик аспектта тикшерү этнос төркеме буларак, себер бохаралыларына тулырак тарихи-мәдәни характеристика бирергә һәм Көнбатыш Себернең мәдәнияте һәм тарихы турындагы фәнни күзаллауларны киңәйтергә мөмкинлек бирәчәк.

Лингвистик һәм культурологик күзлектән чыгып караганда, метрика кенәгәләренең текстларының бай эчтәлекле булуы аларга татар теленең рәсми-эш кәгазьләре стилен өйрәнүдә кыйммәтле төбәк чыганагы итеп карарга мөмкинлек бирә. Шулай ук аларда диалектизмнарның еш очравын, вариатив формаларның һәм лексемаларның кулланылышы чагылуын да билгеләп үтәргә кирәк. Бигәрк тә әлеге метрика кенәгәләрендә антропонимнарның һәм туганлык мөнәсәбәтләрен чагылдыра торган апеллятив лексиканың зур фонды урын ала. Моннан тыш, сакланып калган кулъязмалар милли телгә төрле телләрдән алынмаларның керүе һәм аларның татар теленә ярашуы һәм кодификацияләнүе турында фикер йөртү мөмкинлеген бирә.

**Әдәбият**

ГБУТО ГА в г. Тобольске[1]. Мечеть Комаровских юрт Тобольского уезда Тобольской губернии. Ф.И641.

Гиганов И. Словарь российско-татарский, собранный в Тобольском главном народном училище. – СПб.: Императорская Академия Наук, 1804.

ГКУ «Национальный архив Республики Башкортостан». Ф. 295, оп. 9, д. 692. Тобольская губерния. 1851 г.

РГИА[2]. Ф.1291, оп. 84, д. 225. Земский отдел Министерства внутренних дел. 1911 г. По указу Сената по жалобе доверенного бухарцев Бухарской волости.

РГИА. Ф.1291, оп.84, д.120. Земский отдел Министерства внутренних дел. 1911 г. По прошению бухарцев, юрт Вагайских и Медянских.

Русско-татарский разговор. Практические уроки русского и татарского языка. На русском языке и на наречии татар Тобольской губернии. Издание Тобольского Комитета Православного Миссионерского Общества. – Тобольск: Типография Епар. Братства, 1905. – 88 с.

Список населенных мест Тобольской губернии: [составлен по сведениям на 15 июля 1909 года, полученным от уездных исправников и волостных правлений]. Тобольск: издание Тобольского губернского статистического комитета, 1912.

Тумашева Д.Г. Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. – Казань: Издательство Казанского университета, 1977. – 294 с.

[1]Государственное бюджетное учреждение Тюменской области Государственный архив в г. Тобольске
[2] Российский государственный исторический архив.

# МЕТРИЧЕСКИЕ ЗАПИСИ XIX – НАЧАЛА XX ВЕКА КАК ИСТОРИКО-ЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ ИСТОЧНИК

**Гузель Чахваровна Файзуллина,**
Тюменский государственный университет,
Россия, 625003, г. Тюмень, ул. Володарского, д. 6,
utgus@mail.ru.

**Энзе Ханафиевна Кадирова,**
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова, АН РТ,
Россия, 420111, г. Казань, ул. К. Маркс, д. 12,
enge@inbox.ru.

В статье поднимается вопрос, связанный с изучением письменного наследия коренного тюркоязычного населения Западной Сибири – сибирских татар. Материалом исследования являются метрические книги «на записку родившихся, о браках, разводах и смерти», написанные на старотатарском языке. Хронологические рамки исследования определяются периодом с 30-х гг. XIX в. до начала XX в.

В мусульманских книгах сохранились сведения о проживании в юртах этнически и сословно неоднородного населения: староясачных татар, оброчных чувальщиков, служилых татар, а также переселенцев из Средней Азии – бухарцев (сартов). Предметом исследования являются структура и содержание метрических записей (на примере мечетных книг юрт Комаровских Бухарской волости Тобольской губернии).

Историко-лингвистическое исследование мусульманских метрических (мечетных) книг позволит дать более полную историко-культурную характеристику сибирских бухарцев как этносословной группы и расширит научные представления о культуре и истории Западной Сибири в целом.

**Ключевые слова:** сибирские татары, сибирские бухарцы, метрические записи, Тобольская губерния, Бухарская волость.

Исследование выполнено при финансовой поддержке РФФИ в рамках научного проекта № 20-412-720008 р_а_Тюменская область «Метрические записи XIX – начала XX вв. о тобольских и тюменских бухарцах как историко-лингвистический источник».

DOI: 10.26907/2311-2042-2021-17-2-25-44

# COMPARISONS WITH A "COLOR" COMPONENT AS A MEANS OF HUMAN ASSESSMENT (BASED ON THE TATAR AND RUSSIAN LANGUAGES)

**Ramziya Marsovna Bolgarova**,
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
ramzija5@yandex.ru.

**Raushaniya Sagdatzyanovna Nurmukhametova**,
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
rsagadat@yandex.ru.

This article examines comparative constructions with a color component in the Tatar and Russian languages in a comparative aspect.

The purpose of this research is to study comparisons with color components as a means of describing a person's appearance and character. Examples from the Written Corpus of the Tatar Language, the National Corpus of the Russian Language were used as research materials. Color component comparisons are used to describe natural features of people's appearance and external signs of their physical and psychological state. These figurative means can create either a positive or a negative image, depending on the compared object and image.

The theoretical and practical value of this work is the possibility of using its main results in studying linguoculture and lexicology of the Tatar and Russian languages.

**Key words**: Tatar language, Russian language, comparison, color components, human appearance.

## Introduction

All ideas of people about the world around them are formed in their consciousness and are largely explained by the associative nature of thinking. The image of a person is one of the main images both in depicting the world belonging to all people and in depicting their national world. Therefore, the study of stable comparative linguistic units, depicting people, allows us to fully represent their image reflected in the language.

We must say that the human image is a manifestation of the national perception of the world. Representatives of different cultures have their own ideas of the surrounding environment, perceiving information about the world in their own way. According to Humboldt, "different languages are not only different names for the same subject, but also different views on them" [Humboldt, p. 154]. Therefore, the world image can be verbally described only taking into account national and cultural characteristics of language.

As noted by A. Potebnya, "thanks to the word, a person again recognizes what is in his mind. He simultaneously creates a new world out of chaos and strengthens his power to expand the boundaries of this world" [Potebnia, p. 302].

Stable comparisons are units that are actively used in the Tatar and Russian languages. They contain figurative and expressive speech means, in most cases the emotions of the speaker or writer. As different layers of phraseology, comparisons accumulate the centuries-old experience of the population. Also, comparisons are based on cultural associations, on linguistic and cultural experiences.

## Materials and research methods

Our research is based on examples from the Written Corpus of the Tatar Language and the National Corpus of the Russian Language.

We used the corpus examples describing a person, formed by matching color components that include auxiliary words *кебек (kebek)* and *как (kak)*, which are often used in both languages, and comparisons formed directly with the auxiliary word *төсле (tesle)*.

In the article, we used the method of observation, as well as comparative, descriptive and semantic analyses.

**Discussion**

You can get a great amount of information on a person's appearance by determining one's nationality, gender, age, and giving personal characteristics. In general, the appearance of a person, the features of description speak volumes as to the national culture. Usually, when describing a person, we use both positive and negative connotations. In this work, comparisons with a color component in Tatar and Russian are analyzed as a means of describing and evaluating a person's appearance.

Colors are used to compare someone with a specific object or phenomenon in order to give additional characteristics to the features of a person's external appearance and inner world. Representatives of different cultures perceive and evaluate the same color in different ways depending on the meaning.

There is a deep connection between the symbolism of colors and human consciousness, history, cultural and social life. Colors can express different meanings, evoke different feelings and create associations; thus, they create special and peculiar changes in the human mental world. Associations are connected with the features of personal, national, religious, etc. perception of the world. Since ancient times, people have paid special attention to colors in the beliefs of the people, their ancient legends, works of oral folk art and religious teachings.

A characteristic feature of the color semantics is polysemy. Color contains many different meanings, and these qualities are reflected in set phrases.

Our scientific research is focused on color comparisons that have identity and are often used in the Tatar and Russian languages (colors: *white, black, red, green and blue*).

In the culture of mankind, *white* and *black* are considered to be the most ancient colors. In the Tatar and Russian languages, the names of these colors are encountered quite often in comparisons, which can be explained by their cognitive and cultural significance.

White color

АК (AK)

| | |
|---|---|
| 1) Кар, сөт төсендәге; киресе: кара. | 1) The colors of snow, milk; opposite: black. |
| 2) Үз төсен югалткан, чал, чаларган, көмеш төсле. | 2) Lost its color, gray-haired, silver. |
| 3) Ялтырап торган көмешсыман төстәге, өстеннән никель йөгерткән. | 3) Light silver color, on top of which nickel is applied. |
| 4) Борчылудан, каушаудан, авырудан йөзе үзгәргән, төсе, чырае киткән, агарынган. | 4) A face pale with excitement, confusion, illness, pain. |
| 5) *махс.* Ике яки өч сүздән торган зоологик һәм биологик терминнарның (атамаларның) беренче кисәге. | 5) *prof.* The first part of zoological and biological terms (names), consisting of two or three words. |
| 6) *күч.* Чиста, керсез, пычранмаган, юылган (кием-салым турында). | 6) *fig. m. (figurative meaning).* Clean, not dirty, washed (about clothes). |
| 7) күч. тар. Революциягә һәм Совет хөкүмәтенә каршы булган. | 7) *fig. m. (in the narrow sense).* A man who was against the revolution and the Soviet government. |
| 8) *күч.* Алдынгы; укымышлы, прогрессив. | 8) *fig. m.* Advanced; educated, progressive. |
| 9) *күч.* Язмыйча, буш калдырып, фикернең тәмамланмавына, яшерен эчке мәгънә булуына ишарә иткән [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге]. | 9) *fig. m.* Leaving empty lines, indicating that the thought is not finished, there is a hidden inner meaning [Explanatory Dictionary of the Tatar Language]. |

Б (BELIY), -ая, -ое; бел, бела, бело и бело

| | |
|---|---|
| 1. Цвета снега или мела. | 1. Colors of snow or chalk. |
| 2. *полн.* Светлый, в противоположность чему-н. более тёмному, именуемому чёрным. | 2. *Full m.* Light, as opposed to something darker; opposite: black. |
| 3. *полн.* В первые годы гражданской войны: относящийся к вооружённой борьбе за восстановление законной власти в России. | 3. *Full m.* In the early years of the Civil War: related to the armed struggle for the restoration of legal power in Russia. |
| 4. белый, -ого, муж. То же, что белогвардеец. | 4. The same as the White Guard. |
| 5. *полн.* Со светлой кожей (как признак расы). Цветные и белые (сущ.) | 5. *Full m.* With fair skin (as a sign of race). Colored and white (noun) [Ozhegov's |

| | |
|---|---|
| [Толковый словарь Ожегова]. | Explanatory Dictionary]. |

Associations containing the "white" component in the Tatar language are actively used to describe one's body, face, teeth, hands, hair, beard, mustache, etc. As an object of comparison, words *snow, milk, sugar, cotton, swan, turnip, canva* are often used. For example:

*Иптәшләр, ишкәкләргә ныграк басыгыз! – дип пышылдый Искәндәр, һәм караңгыда аның* ***кар кебек ак тешләре*** *ялтырап китәләр [Татар теленең язма корпусы] (Comrades, pull on the oars harder! - Iskandar whispers, and his* ***teeth, as white as snow****, shine in the darkness [Corpus of Written Tatar]);*

*Йөзләренә таңның алсу төсе кунган,* ***шикәр кебек ак йөзле*** *Любаша аерылышуны үзенчә кичерде [Татар теленең язма корпусы] (Lyubasha, whose face was as pink as the shade of dawn and* ***as white as sugar****, endured the divorce in her own way [Corpus of Written Tatar]);*

*Хәзрәт* ***мамык кебек ак****, йомшак* ***кулларын*** *биреп саубуллашты да җир өстендә йөзгән томан кебек, салмак кына атлап китеп барды [Татар теленең язма корпусы] (Khazret said goodbye, shaking with his* ***fluffy white hands****, and slowly sweeping across the ground like fog [Corpus of Written Tatar]);*

*Көзгегә караганчы ук мин кулларымның* ***сабыйларныкы кебек ак*** *һәм җыерчыксыз булуын күрәм [Татар теленең язма корпусы] (Even without peering in the mirror, I could see that my* ***hands were white*** *and without wrinkles, like babies' [Corpus of Written Tatar]);*

*Вәгъдәгөл карчыкны күргәч, Вера гаҗәпләнеп куйды:* ***башы кар кебек ак****, ник ичмасам бер кара чәче күренсен [Татар теленең язма корпусы] (Vera was surprised to see the old woman Vagdagul, whose* ***hair was as white as snow****, not a single black hair could be seen [Corpus of Written Tatar]);*

*Хәтта шәһәребезнең атаклы галиме, тарих фәннәре докторы Вәли ага үзе дә, куллары белән* ***кар кебек ак чигәләрен*** *кысып, бүлмәдә әрле-бирле йөренә һәм сөйләнә иде...[ Письменный корпус татарского языка] (Even Vali aga himself, a famous scientist, doctor of History, walked up and down the room, hands clutching his* ***temples as white as snow*** *and talking... [Corpus of Written Tatar]);*

*Картның* ***сөт кебек ак сакалы*** *калтыраныйп китте [Татар теленең язма корпусы] (The old man's* ***beard, as white as milk****, quivered [Corpus of Written Tatar]);*

*Юк, ятим булмас аның әтисе кебек үк киң маңгайлы, зур кара күзле,* ***кызлар кебек ак йөзле****, озын керфекле улы [Татар теленең язма корпусы] (No, his son with a wide forehead, same as his father's, and big black eyes, with long girl-like eyelashes and a* ***white face****, will never be an orphan [Corpus of Written Tatar]);*

***Тәне шалкан кебек ак*** *һәм тыгыз, җилкәләре киң иде Гафурның [Татар теленең язма корпусы] (Gafur's body was* ***white*** *and dense,* ***like a turnip****, and his shoulders were broad [Corpus of Written Tatar]).*

In the previous examples, images of snow, milk, sugar, cotton, baby, etc. have a positive connotation. These standards coincide with the definitions given in the dictionaries.

*Менә мин нишлим, менә ник* ***битем киндер кебек ак****, менә ник минем күзләрем тиле кешенеке кебек! [Татар теленең язма корпусы] (What should I do?! My face is* ***as white as canvas****, and my eyes are like those of a stupid person! [Corpus of Written Tatar];*

*Нәрсә булды,* ***йөзең чүпрәк кебек ак****? – диде аңа тегесе [Татар теленең язма корпусы] (What's happened, you have turned pale (your face has become* ***as white as a rag****)? – he said [Corpus of Written Tatar]).*

In these comparisons, white is also used, but through the images of canvas and rags, so a person's appearance is negatively assessed.

White has a strong emotional impact on human consciousness, because it creates associations with light, day and purity. All these examples prove that white is used for a positive characterization. Therefore, due to the "white" component these comparisons are used to describe the purity of the human soul and to characterize a person positively. For example:

*Шул мизгелдә сине җиргә төшереп, теге* ***Хозыр Ильяс кебек ак Бабай****, елмаймый-нитмми, китаплар артыннан килеп чыга һәм синең кулыңа озынлыгы ике метрдан да ким булмаган очлы таяк тоттыра [Татар теленең язма корпусы] (At this moment, as if bringing you to your senses,* ***a white Old Man****, reminiscent of the prophet Ilyas, appears from behind the bookshelves and holds out a stick at least two meters long. [Corpus of Written Tatar]);*

*Зөбәйдә –* ***кар кебек ак****, су кебек пакь* ***кыз*** *[Татар теленең язма корпусы] (Zubeida is* ***as white as snow****, a girl, as pure as water [Corpus of Written Tatar]);*

*__Ул__ да бүген нәкъ шул __каен кебек ак__ иде, биек иде һәм бәхетле иде, кичәге көнне кичәгесендә калдырып, бүген чиксез бәхетле иде [Татар теленең язма корпусы] (Today she was just as happy, tall and __as white as a birch__, leaving yesterday behind, today she was immensely happy [Corpus of Written Tatar]).*

In the Tatar language, the word "white" in combination with the words *ash* and *oil* in one phrase creates a certain image. For example:

*Кадермәтнең __йөзе көл кебек ак__, иреннәре күгәреп каткан...[Татар теленең язма корпусы] (Kadermet was __as pale as ash__, and his lips turned blue ... [Corpus of Written Tatar]);*

*__Йомарлак май кебек ак тезләр__ен каплар-капламас чуар күлмәк...[Татар теленең язма корпусы] (Dress barely covering her __knees as white as butter__ [Corpus of Written Tatar]).*

In these comparisons a person's features can acquire both positive and negative connotations, depending on the context.

In the Russian language, comparisons with the "white" component are often used when depicting one's body, face, hair, beard, etc. In the Explanatory Dictionary of the Russian Language, white is used in comparisons with something snowy and chalky. Therefore, as an object of comparison, the images of *snow, chalk, paper, cotton, milk, flour, birch*, etc. are also widespread. For example:

*Его атласные __волосы, белые, как снег,__ были расчесаны; он разглаживал седую бороду [Национальный корпус русского языка] (His silky __hair, as white as snow,__ was combed; he was smoothing his gray beard [Russian National Corpus]);*

*Подошёл __Василий__ совсем близко: лица на нём нету, __белый, как мел__, глаза дикие; говорить начал – голос обрывается [Национальный корпус русского языка] (__Vasily__ came very close: his face was __as white as chalk__, his eyes were wild; when he began to speak – his voice broke off [Russian National Corpus]);*

*Нюрка стала реветь без слов, а __Володя, белый как бумага__, лепетал и точно боролся с кем-то, кто подшибал его под коленки, опрокидывал навзничь и душил [Национальный корпус русского языка] (Nyurka began to weep without saying a word, and __Volodya, as white as paper__, was babbling and definitely fighting someone who kicked him under his knees, knocked him over and was strangling [Russian National Corpus]);*

*Оксана обернулась – брат был __с лица белый как простыня__ и белой же рукой указывал на что-то там, на земле [Национальный корпус русского языка] (Oksana turned around - her brother's __face__ was __as white as a sheet and with his white hand__ he was pointing at something on the ground [Russian National Corpus]);*

*Номер вполне мог стать смертельным, и __Виталий__ действительно на миг потерял сознание, но все же опомнился и, __белый, как полотно__, самоотверженно довел до конца эпизод с канарейкой [Национальный корпус русского языка] (The act could well have become fatal, and __Vitaly__ really lost consciousness for a moment, but nevertheless came to his senses and, __as white as a sheet__, selflessly completed the episode with the canary [Russian National Corpus]);*

*Бросила взгляд на Рапопорта – __он белый как скатерть__ [Национальный корпус русского языка] (I glanced at Rapoport - he was __as white as a tablecloth__ [Russian National Corpus]).*

In Russian, the words harrier, deceased, death, etc. are more often used to create special images. For example:

*Седые __волосы, белые как лунь__, бритое лицо – некрасивое, но интересное каждою морщинкой [Национальный корпус русского языка] (His gray __hair__ was as __white as a harrier__, his shaved face was ugly, but interesting with its every wrinkle [Russian National Corpus]);*

*__Фомич__ сидел посреди дороги, __белый как покойник__, и еле дышал, убитый жарой [Национальный корпус русского языка] (__Fomich__ was sitting in the middle of the road, __as white as a dead man__, and could hardly breathe because of heat [Russian National Corpus]);*

*Хмель из плотника вышибло, а рядом__, белый, как смерть__, стоял __шофер__ [Национальный корпус русского языка] (The carpenter immediately sobered up, and next to him, __as white as death__, was the __chauffeur__ [Russian National Corpus]).*

In Russian, the whiteness of a person's face is associated with death, through the images of death and the deceased not only the appearance of a person is described, but also his/her physical condition and internal worries.

Obviously, both languages have similar lexical-thematic groups of images as these examples show. Comparisons with a "white" component in Tatar and Russian are used to describe human hair (gray hair), teeth, complexion,

as well as one's physical and emotional state (illness, fatigue, anxiety, fear, etc.).

Black color

КАРА (KARA)

| | |
|---|---|
| 1) Корым төсендәге; иң караңгы төсле. | 1) Ash color; the darkest color. |
| 2) Куерак, караңгырак төстәге. | 2) Thick, darker color. |
| 3) Караңгы; яктылык төшми торган, куе, калын. | 3) Dark; a place where no light falls. |
| 4) Негроид расаның билгесе буларак, ак тәнлеләрдән нык аерылган караңгы төстәге. | 4) As a sign of the Negroid race, distinguishing it from the white-skinned. |
| 5) Тумыштан каратутлы, чәче һәм тән төсе башкаларныкыннан караңгырак булган. | 5) Dark by nature, hair and skin color, darker than others. |
| 6) Кояш астында озак булудан, җылы якларда яшәүдән аклыгын югалткан, каралган, кояшта кызган (кешедә бит, тән төсе тур.). | 6) The one who has lost whiteness because of a long stay in the sun, life in warm regions (human face, skin color). |
| 7) Керле, пычрак, юынмаган. | 7) Dirty, not washed. |
| 8) Сөт кушылмаган (чәй, кофе һ.б.ш.). | 8) Without milk (tea, coffee, etc.). |
| 9) иск. Махсус исерткеч итеп эшләнә торган (кымыз). | 9) Outdated: Made specifically to treat intoxication (koumiss). |
| 10) Морҗасыз, төтене махсус тишектән – төнлектән чыга торган (мунча, өй тур.). | 10) Without a chimney (sauna, home tour). |
| 11) иск. Хезмәтчеләр тора торган, кышын терлек-туар кертелә торган (өй, бүлмә тур.) [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге]. | 11) Outdated: A place to live for workers in the summer and livestock in the winter (about a house, a room). [Explanatory Dictionary of the Tatar Language]. |

ЧЁРН (CHERNIY), -ая, -ое; чёрен, черна, черно и чёрно.

| | |
|---|---|
| 1. Цвета сажи, угля. | 1. Colors of soot, coal. |
| 2. полн. Тёмный, в противоп. чему-н. более светлому, именуемому белым. | 2. *Full m.* Dark contrasted to something lighter called white. |
| 3. Принявший тёмную окраску, потемневший. | 3. The one accepting dark color, darkened. |
| 4. полн. В старину: то же, что курной. Чёрная баня. | 4. *Full m.* In the old days: the same as a house heated by a stove without a chimney. A black bath. |
| 5. перен. Мрачный, безотрадный, тяжёлый. | 5. *Fig. m.* (figurative meaning). Gloomy, bleak, heavy. |
| 6. полн., перен. Преступный, злостный. | 6. *Fig. m.* Criminal, malicious. |
| 7. полн. Не главный, задний (о входе, ходе). | 7. Not the main one, the back one (about an entrance, a passage). |
| 8. полн. О труде: физически тяжёлый и неквалифицированный. | 8. *Full m.* About work: physically difficult and unskilled. |
| 9. полн. Принадлежащий к непривилегированным, эксплуатируемым классам общества (устар.). | 9. *Full m.* Belonging to the underprivileged, exploited classes of society (obsolete). |
| 10. полн. На Руси в 1217 вв.: государственный, не частновладельческий. | 10. *Full m.* In Russia in 1217 centuries: belonging to the state, not private. |
| 11. полн. С тёмной кожей (как признак расы), чернокожий [Толковый словарь Ожегова]. | 11. *Full m.* With dark skin (as a sign of race), black-skinned [Ozhegov's Explanatory Dictionary]. |

Since ancient times, people have associated black with nights and darkness. This color in the human mind is associated with danger. Therefore, comparisons that include this color are actively used to create negative images in both languages. For example:

***Чырайлары корым сарган кебек кара*** *күйгән [Татар теленең язма корпусы] (Their faces are as* ***black as soot*** *[Corpus of Written Tatar])*

*Берни дә барып чыкмагач,* ***шайтан кебек кара йөзле****, сасы сарымсак белән тәмәке исе аңкытып торган урыс аны этә-төртә урамга куып чыгарды [Татар теленең язма корпусы] (When nothing came of it,* ***a Russian, as dark as the devil****, smelling of garlic and tobacco, pushed him out into the street [Corpus of Written Tatar]);*

*Аннан таза гәүдәле,* ***сумала кебек кара чырайлы****, кысык күзле, чәче-кашы ат кылын хәтерләткән адәм күренде [Татар теленең язма корпусы] (From there appeared a stocky man with his* ***face as black as pitch,*** *with narrow*

*eyes, hair and eyebrows, reminiscent of a horse's mane [Corpus of Written Tatar]);*

*Чырайлары чытык, **битләре кайрак кебек кара** янган [Татар теленең язма корпусы] (Their faces were wrinkled and **as black as emery** [Corpus of Written Tatar]);*

*Совсем как этот: усатый, **черный, как головешка**, со злым лицом [Национальный корпус русского языка] (Just like this one: moustached, **as black as a firebrand**, with an evil face [Russian National Corpus]);*

*Иногда приходил **черный как туча**, вздрагивал от каждого шороха [Национальный корпус русского языка] (Sometimes he came **as black as a black cloud**, flinching at every rustle [Russian National Corpus]);*

*В центре группы на охапке сена возлежал **черный, как негр, детина** с одной ногой [Национальный корпус русского языка] (In the center of the group, on an armful of hay, was reclining **a big one-legged man, as black as a Negro** [Russian National Corpus]);*

***Арап** лежал в гробу в морском мундире времени Екатерины, **черный как уголь...** [Национальный корпус русского языка] (**The blackamoor** lay in a coffin in a naval uniform of Catherine's time, and he was **as black as coal** ... [Russian National Corpus]);*

Comparisons with this color can be found in the descriptions of hair, eyes and eyelashes in both languages. The following words are actively used in set phrases: *night, resin, coal, earth, cloud, bird cherry, currant, raven, raven wings, Arab, gypsy*, etc. For example:

***Күзләре** минекенә охшаган, **төн кебек кара** [Татар теленең язма корпусы] (**Eyes** like mine, as **black as night** [Corpus of Written Tatar]);*

*Чигә **чәчең** кара иде, / **Сумала кебек кара** [Татар теленең язма корпусы] (Your **hair** was black, / **as black as resin** [Corpus of Written Tatar]);*

*Алланып торган кояш чыгышыннан китерелгән җитез егетнең **шомырт кебек кара күзләренә** кылдан нечкә итеп очланган инәләр кададылар, ди [Татар теленең язма корпусы]( A lively guy rose with the first rays of the dawn, his eyes **as black as bird cherries** as if pierced by very sharp needles, thinner than a string [Corpus of Written Tatar]);*

*Ул арада сигез-ун яшьлек яланаяк, яланбаш, үзләре **ком гарәбе кебек кара янган** ике **малай** килеп чыкты [Татар теленең язма корпусы] (Meanwhile, two boys, about eight or ten years old, appeared, barefoot, bareheaded and burnt out in the sun, both **as black as guides in the desert** [Corpus of Written Tatar]);*

***Чегән кебек кара чәчле**, кара тәнле булганы өчен генә түгел, ә эшчеләр арасында иң яше булганга да, аңа шулай дип дәшәләр иде [Татар теленең язма корпусы] (That was his name not only because he was **black-haired, like a gypsy**, but also because he was the youngest among the workers [Corpus of Written Tatar]);*

*Телефон баганасыдай озын, **мунча ташы кебек кара Хәниф** иде ул [Татар теленең язма корпусы] (Hanif was as long as a telegraph pole, **as black as a bath stone** [Corpus of Written Tatar]);*

*Икенчесе егерме-егерме биш яшьләрдәге егет, ә яңакларында **кара урман кебек кара сакал** [Татар теленең язма корпусы] (The second young man was in his twenties, and on his cheeks he had **a beard as black as a thick forest** [Corpus of Written Tatar]);*

***Төн кебек кара**, ишелеп төшкән **чәчләрен** төзәтеп куйды [Татар теленең язма корпусы] (He straightened his **hair as black as night** [Corpus of Written Tatar]);*

***Күмер кебек кара чәчләре** арасында көмешсу көл сибелгән кебек [Татар теленең язма корпусы] (It seemed that his hair, **as black as coal,** was sprinkled with silvery ash [Corpus of Written Tatar]);*

*Аннан калын гына гәүдәле, тулы битле, кысыграк күзле бер кеше төште, **кашы, чәчләре сумала кебек кара** [Татар теленең язма корпусы] (A fat, plump-faced man with narrow eyes, **pitch-black eyebrows and hair** descended from there [Corpus of Written Tatar]).*

In the Russian language, the same images are actively used. For example:

*Лица их были смуглые, носы приплюснутые и губы толстые, **глаза чёрные, как смоль**, равно как и волосы, висящие прядями, иные были с редкими бородами, иные же и вовсе без бород; в разные части лица были у них воткнуты длинные косточки и вставлены камешки [Национальный корпус русского языка] (Their faces were swarthy, their noses were flattened and their lips were thick, their eyes were **pitch-black**, as well as their hair hanging in strands, some wore sparse beards, others without beards at all; they had long bones and pebbles stuck in different parts of their faces [Russian National Corpus]);*

*И я, подчиняясь моему порыву, наклонилась к ней и нежно поцеловала ее **глаза, черные, как ночь**, и горящие, как алмазы [Национальный*

*корпус русского языка] (And I, obeying my impulse, bent down to her and tenderly kissed her* ***eyes, as black as night*** *and as shiny as diamonds [Russian National Corpus]);*

*Передок занимал квадратный,* ***черный как ворон мужик****... [Национальный корпус русского языка] (The front end was occupied by a square-shaped* ***man, as black as a raven*** *... [Russian National Corpus]);*

*Лицо у него было смуглое, два черных глаза горели, как угли, не покрытые париком короткие* ***волосы, черные, как воронье крыло****, вились мелкими кольцами, и весь он был одет в черное [Национальный корпус русского языка] (His face was swarthy, his two black eyes shone like coals, his short hair was not covered with a wig, it was* ***as black as a crow's wing****, curled in small rings, and he was all dressed in black [Russian National Corpus]);*

***Лёва*** *высокий, стройный,* ***чёрный, как цыган****, Олеся ему по плечо, белолицая русалочка с льняными волосами... [Национальный корпус русского языка] (****Lyova*** *is tall, slender and as* ***black as a gypsy****, Olesya is shorter, a white-faced mermaid with flaxen hair ... [Russian National Corpus]).*

With the help of this color, both a positive and negative image can be created, depending on the ratio of the object and the image.

When describing a person's appearance (hair, eyes, eyebrows, eyelashes), black often makes a positive impression, it creates a negative image when depicting people's physical condition or their inner experiences.

Red color

К З (KYZYL)

| | |
|---|---|
| 1) Спектрның төп төсләреннән иң беренчесе төсле, кан төсендәге. | 1) the color of blood, the color of the very first of the primary colors of the Spectrum. |
| 2) сөйл. оны, төкләре кызгылт көрән, куе җирән төсле (сыер, бозау төсе тур.). | 2) *colloquial*: Wool, hair is red-brown, with a dark red color (about the color of cows, calves). |
| 3) Кызыл төс алган, беркадәр кан төсе кергән, кызарган. | 3) turned red, blushed somewhat. |
| 4) тар. Октябрь революциясенә, революциядә катнашучыларга, большевикларга, революцион эшчәнлеккә бәйләнешле; Советлар Союзына, Кызыл Армиягә караган. | 4) *narrow meaning*: Related to the October Revolution, participants in the revolution, the Bolsheviks, revolutionary activities; belonging to the Soviet Union, the Red Army. |
| 5) иск. тар. Җәдитчеләр хәрәкәтендә катнашучы, җәдитчелек тарафында булган. | 5) *outdated, narrow meaning*: A member of the Jadid movement in Jadidism. |
| 6) күч. Һич тайпылмыйча билгеле бер карашны яклаучы, эзлекле тарафдар булган, ортодокс булган. | 6) *figurative meaning*: Orthodox, resistant follower of a particular point of view. |
| 7) Ботаника, зоология, минералогия кебек фәннәрдәге кайбер тезмә терминнарның беренче компоненты буларак кулланыла. | 7) used as the first component of some combination terms in such sciences as botany, zoology, mineralogy. |
| 8) Югары пробалы, саф (кыйммәтле металлар тур.). | 8) the highest standard, pure (about precious metals). |
| 9) Югары уку йортын "бик яхшы" билгеләре белән генә тәмамлаган студентларга бирелә торган (диплом тур.) [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге]. | 9) referred to university graduates who graduated with honors (about a diploma). [Expressive Dictionary of the Tatar Language]. |

КРАСН (KRASNIY), -ая, -ое; -сен, -сна, -сно и -сно.

| | |
|---|---|
| 1. (-сно). Цвета крови, спелых ягод земляники, яркого цветка мака. | 1. The colors of blood, ripe strawberries, bright poppy flowers. |
| 2. полн. Относящийся к революционной деятельности, к советскому строю, к Красной Армии. | 2. *Full m*. Related to revolutionary activities, to the Soviet system, to the Red Army. |
| 3. Употр. в народной речи и поэзии для обозначения чего-н. хорошего, яркого, светлого. | 3. Used in folk speech and poetry to denote something good, bright, beautiful. |
| 4. полн. Употр. для обозначения наиболее ценных пород, сортов чего-н. (спец.). | 4. *Full m*. Used to designate the most valuable breeds, varieties of something. (specialist.). |
| 5. красный, -ого, муж. | 5. Supporter or |

| | |
|---|---|
| Сторонник или представитель большевиков, их революционной диктатуры, военнослужащий Красной Армии [Толковый словарь Ожегова]. | representative of the Bolsheviks, their revolutionary dictatorship, a soldier of the Red Army [Ozhegov's Explanatory Dictionary]. |

Red is distinguished by its brightness and beauty among other colors, this color has many figurative meanings. For many peoples, it is a sacred color, often associated with blood and fire.

In red component comparisons, we find the names of garden and field flowers, berries, fruit and vegetables. For example:

*Оятыннан **гөл кебек кызыл йөзе**, Ак киемнән, алтын таҗ кигән үзе [Татар теленең язма корпусы] (His **face** was **as red as a flower**, and he was wearing white clothes and a golden crown [Corpus of Written Tatar]);*

*Кырысрак сыман күренгән хатын бала янында бөтенләй эреде, ул аны иркәли, **алма кебек кызыл битләреннән** үбә башлады [Татар теленең язма корпусы] (The woman, who looked stricter, changed completely when having the child around, she was caressing him, kissing him on **the cheeks as red as apples** [Corpus of Written Tatar]);*

*Ә анда, авызын ерып, **җиләк кебек кызыл чырайлы** Әнвәр абый бүрәнә юнып маташа иде [Татар теленең язма корпусы] (And there, with **a face as red as a berry**, Anvar aby, smiling broadly, was hewning a log [Corpus of Written Tatar]);*

*Кызый чибәр, аның карлыгандай кара күзләренә, **чия төсле кызыл иреннәренә**, алма кебек тыгыз, түгәрәк күкрәкләренә сокланып карап тормыйча түзеп булмый [Татар теленең язма корпусы] (The girl is beautiful, it is impossible to avoid looking into her eyes as black as currants, **lips** as **red as cherries, and breasts as** lush as apples. [Corpus of Written Tatar]);*

***Йөзе чөгендер кебек кызыл** иде [Татар теленең язма корпусы] (The **face** was as **red as beetroot** [Corpus of Written Tatar]).*

In Russian, in comparisons related to this group, there are often names of animals and fiery images in addition to the names of flowers, fruit and vegetables; this color has much more metaphorical meanings. For example:

***Красный, как пион**, **Соткин** смотрел в холодное лицо унтера едва не умоляющими глазами [Национальный корпус русского языка] (**Red as a peony, Sotkin** gazed into the sergeant's cold face with almost pleading eyes [Russian National Corpus]);*

*Быстро исчезнет с него тогда человеческий облик: обрюзглая, посиневшая физиономия, **губы красные, как огонь**, и мутные глаза выразят в телесных формах неутолимую тоску его души [Национальный корпус русского языка] (Then his human appearance will quickly disappear: his flabby, blue face, his **lips as red as fire**, and dull eyes will express the unquenchable melancholy of his soul in bodily forms [Russian National Corpus]);*

*Какой **он** сидел тогда **красный, как помидор** спелый, как из города Омского явился, думал я, ему веку не будет…[ Национальный корпус русского языка] (He was **red, like a ripe tomato**, as if he came from the city of Omsk, I thought, he wouldn't last long... [Russian National Corpus]);*

***Он** смутился и стал **красный, как свекла** [Национальный корпус русского языка] (He was embarrassed and turned **red as beetroot** [Russian National Corpus]);*

*Несколько справившись с собою, весь **красный как рак**, **он** объявил, что счёл долгом поднять рубашечку, лично принести её… [Национальный корпус русского языка] (Having calmed down a little, all **red as a crawfish**, he announced that he considered it his duty to pick up the shirt and personally bring it ... [Russian National Corpus]);*

*Подкосились снова ноженьки у Наташи, а **Василий** уже идет к ней, идет – весь **красный, как огонь**, от крови, глаза горят у него, как костры в темной ночи, – и он к ней руки тянет [Национальный корпус русского языка] (Natasha's legs yielded, and Vasily was already walking towards her, walking - all as **red as fire** with blood, his eyes burning like bonfires in a dark night - and he was reaching out to her [Russian National Corpus]);*

*А только что **он** был **красный, как пожар** [Национальный корпус русского языка] (And just before it he was **as red as fire** [Russian National Corpus]).*

Comparisons in this group create a positive image when describing people's lips, eyes, nose and complexion, reflecting the physical or spiritual state of a person, and, on the contrary, they can be used to show the negative attitude of the writer or storyteller.

Green color
ЯШ (YASHEL')

| | |
|---|---|
| 1. Спектрда төп төсләрнең берсе – зәңгәр белән сары арасындагы төс; үлән, үсемлек, яфрак төсе.<br>2. Үлән үскән, яшеллек каплаган [яшел болын].<br>3. Үләннән, яфрактан торган [яшел азык]. Ашарга яраклы үләннәрнең (кузгалак, кычыткан һ.б.ш.) яфрагыннан әзерләнгән. яңа чабылган, яңа өзелгән [яшел печән]. | 1. One of the primary colors in the spectrum is a color between blue and yellow; the color of herbs, plants, leaves.<br>2. Covered with greenery or grass [a green meadow].<br>3. Consisting of grass or leaves [green food]. Made from the leaves of edible herbs (reeds, nettles, etc.), freshly cut grass [green]. |
| 4. Җиләк-җимеш, ашлык һ.б.ш. тур.: өлгермәгән, җитлекмәгән. рәв. Өлгермәгән килеш [арыш яшелрәк урылган]. | 4. Fruit and berry, grain, etc.: unripe [green rye]. |
| 5. күч. Бик яшь һәм тәҗрибәсез [бераз яшьрәк һәм яшелрәк булса да] [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005, б. 738]. | 5. *Fig. m.* Very young and inexperienced [Dictionary of the Tatar Language, 2005, p. 738). |

З ЁН (ZELENIY), -ая, -ое; зелен, зелена, зелено, зелены и зелены.

| | |
|---|---|
| 1. Цвета травы, листвы.<br>2. О цвете лица: бледный, землистого оттенка (разг.).<br>3. полн. Относящийся к растительности; состоящий, сделанный из зелени (во 2 и 3 знач.). | 1. Colors of grass, foliage.<br>2. Complexion: pale, earthy shade (colloquial).<br>3. Vegetation; consisting of greenery. |
| 4. О плодах: недозрелый [Толковый словарь Ожегова]. | 4. About unripe fruit [Ozhegov's Explanatory Dictionary]. |

The "green" component comparisons are rare in the Tatar and Russian languages. In both languages, they are usually used to describe human eyes, plants, precious stones (emerald, malachite), names of animals, etc. For example:

*Бу хәбәрне ишеткәннән соң, Поцелуйкин, кулларын угалап, утырган урынында сикереп куйды,* ***мәченеке кебек яшел күзләре*** *кечерәеп, җыерчыклар эчендә тәмам югалып калды, томшык борыны тагын да нечкәреп киткәндәй булды [Татар теленең язма корпусы] (When Potseluikin heard this news he sprang up rubbing his hands. His* ***green, catlike eyes*** *were closed, it was difficult to see them among the wrinkles, and his beak-like nose looked even smaller [Corpus of Written Tatar]);*

*Рәбиганың яшел болыннардагы* ***күлләрнең суы төсле яшел күзләре*** *минем каршымда ич...[Татар теленең язма корпусы] (Rabiga's eyes,* ***as green as lakes in the valley****, happened to be opposite mine. [Corpus of Written Tatar]);*

*Менә ни төсле икән аның күзләре!* ***Малахит ташы төсле яшел*** *[Татар теленең язма корпусы] (That's the colour of her eyes!* ***The green colour of malachite*** *[Corpus of Written Tatar]);*

*Ул сарыктан кеше ясаудан ләззәт таба, ә син аның белән янәшә булудан, аның* ***җәй төсле яшел күзләренә*** *рәхәтлек кичерәсең [Татар теленең язма корпусы] (He enjoys the fact that he can fool a person, and you enjoy looking into his* ***eyes as green as summer****. [Corpus of Written Tatar]);*

*У них были совершенно одинаковые глаза —* ***зеленые, как крыжовины****, в светлых ресницах [Национальный корпус русского языка] (They had exactly the same* ***eyes – as green as gooseberries****, with pale eyelashes [Russian National Corpus]);*

*Увидел, что она мулатка, что плечи у нее мягкие и округлые, а* ***глаза зеленые, как у кошки*** *[Национальный корпус русского языка] (I saw that she was a mulatto, that her shoulders were soft and round-shaped, and her* ***eyes were as green as cats'****[Russian National Corpus]);*

*Лысый безрукий верзила.* ***Глаза зеленые, как трава*** *[Национальный корпус русского языка] (Bald, armless bruiser. His eyes were* ***as green as grass*** *[Russian National Corpus]);*

*– Только нос немножко широк да* ***глаза зеленые, как у ящерицы*** *[Национальный корпус русского языка] (– Only the nose is a little too wide and his* ***eyes are as green as lizards'*** *[Russian National Corpus]).*

In most comparisons, green eyes produce a positive impression, in images with a negative connotation, on the contrary, the appearance of a person and his inner world are shown in a disagreeable way.

Blue color

Зәңгәр (Zangar)

| | |
|---|---|
| 1. 1) Спектрда яшел белән күк арасындагы төп төсләрнең берсе – күк йөзенең аяз көндәге ачык төсе, диңгез төсе.<br>2) күч. Ачы, югары тондагы; көчле, чәрелдәп торган.<br>2. и. мәгъ. 1) Зәңгәр төс, зәңгәр буяу [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге]. | 1. One of the main colors between green and violet in the spectrum; the color of the clear sky, the color of the sea.<br>2) *Fig. m.:* a nasty, high tone; strong, shrill.<br>2. Blue color, blue paint [Explanatory Dictionary of the Tatar Language]. |

СИНИ (SINIY), -яя, -ее; синь, синя, сине.

| | |
|---|---|
| 1. Имеющий окраску одного из основных цветов спектра среднего между фиолетовым и зелёным.<br>2. О коже: сильно побледневший, приобретший оттенок этого цвета [Толковый словарь Ожегова]. | 1. Having a color of one of the primary colors of the spectrum in the middle between violet and green.<br>2. About the skin: very pale, acquiring a shade of this color [Ozhegov's Explanatory Dictionary]. |

In comparisons of the Tatar and Russian languages, the main function of blue is to depict the color of eyes. In addition, it is used in comparisons to reveal not only the color, but also the shape of eyes, and a person's inner experience. In both languages, it often describes *sea, lake, water, air, sky, flower, field*, etc. For example:

***Су кебек зәңгәр күзле****, җирән чәчле, ди, үзләре [Татар теленең язма корпусы] (They say they have* ***water-blue eyes*** *and red hair. [Corpus of Written Tatar]);*

***Төпсез күл кебек зәңгәр күзләре*** *сөйкемле генә карый иде [Татар теленең язма корпусы] (****Blue, like a bottomless lake, her eyes*** *looked at me sweetly [Corpus of Written Tatar]);*

***Кыр чәчкәсе кебек зәңгәр күзле*** *кыз! [Татар теленең язма корпусы] (A girl with* ***eyes as blue as a wildflower****! [Corpus of Written Tatar]);*

***Кыр чәчәге төсле зәңгәр күзләрендә*** *борчылу [Татар теленең язма корпусы] (There was anxiety in her* ***eyes as blue as a wildflower****. [Corpus of Written Tatar]);*

*Ятаклар аслы-өсле куелган бүлмәчеккә төшсәң, шул ук таныш йөзләргә, озынча, кылычтай, төрчекле борынга, нәселле этнеке төсле тырпаеп торган яисә башка ябышкан колакка, табигать биргән төсен отыры үзгәртми торган өлгергән борчактай соры,* ***күк йөзе төсле зәңгәр күзләргә****, хатын-кыз турында тәмсез мәзәк сөйләргә җайланган чапылдык авызларга юлыгасың [Татар теленең язма корпусы] (If you go down to a small room covered with soot, you can meet people with sharp and long, like a blade, noses, with ears sticking out like those of a thoroughbred dog, with* ***eyes as blue as the sky*** *that do not fade with time, people who tell strange jokes about women. [Corpus of Written Tatar]);*

*Туп-туры күзгә карап алулары, алсу битләре, матур колак яфраклары,* ***аяз күк кебек зәңгәр күзләре****, озын, бөгелеп торган керфекләре, аяк атлаулары...[Татар теленең язма корпусы] (Look straight into her eyes, at her pink cheeks, beautiful ears, her* ***eyes are as blue as the clear sky****, her eyelashes are long, curved, her steps ... [Corpus of Written Tatar]);*

*Халкы да матур, егетләрнең күбесе озын буйлы, калын бәдәнле, кыю карашлы; кызлары елга камышыдай зифа буйлы,* ***төпсез диңгез кебек зәңгәр күзлеләр*** *[Татар теленең язма корпусы] (And the people are beautiful, many guys are tall, slender built, with a confident look; their daughters are slender as reeds, with* ***eyes as blue as a bottomless sea*** *[Corpus of Written Tatar]);*

*Чөенке борынлы, сипкелле,* ***күк әчү ташы кебек зәңгәр күзле****, шомырт кара чәчле кыз бу озын чәчле ирнең ушын алды,* ***күл өсте кебек зәңгәр*** *хәзер аның* ***күзләре*** *[Татар теленең язма корпусы] (A girl with a snub nose and freckles,* ***her eyes as blue as the sky****, her hair as black as a bird cherry, left the long-haired man without a word. Now his eyes were* ***as blue as the surface of a lake****. [Corpus of Written Tatar]);*

*Остается летний день, шевелящий листочки, березки, белые, как облака,* ***глаза, синие, как небо*** *над облаками…[Национальный корпус русского языка] (There remains a summer day, stirring leaves, birches as white as clouds,* ***eyes as blue as the sky*** *above the clouds ... [Russian National Corpus]);*

***Синие, как небо*** *Памира,* ***глаза*** *Люды радостно сверкали, когда вбежала она в отдел археологии, бросила на стол две золотистые монетки и торжествующе сказала... [Национальный корпус русского языка] (Luda's* ***eyes, as blue as the*** *Pamir* ***sky****, sparkled with joy when she rushed into the archeology department, threw two*

*gold coins on the table and triumphantly said ... [Russian National Corpus]);*

***Глаза** у нее **синие, как цветочки**, и смотрела она до слез доверчиво [Национальный корпус русского языка] (Her **eyes** were **as blue as flowers**, and she gazed so trustingly one could cry [Russian National Corpus]);*

*Наконец, она вздохнула и открыла **синие, как фиалки**, **глаза** [Национальный корпус русского языка] (Finally, she sighed and opened her **violet-blue eyes** [Russian National Corpus]);*

*И синие, **синие, как воды родной реки**, **глаза** девушки туманятся теперь слезами [Национальный корпус русского языка] (The girl's eyes, which used to be blue, as blue as the waters of the native river, are now full of tears [Russian National Corpus]);*

*На щеках румянец, что маков цвет. **Глаза** игривые, **синие, как тропическое море** [Национальный корпус русского языка] (Her cheeks blush like poppies. The **eyes** are playful and as **blue as a tropical sea** [Russian National Corpus]).*

In Russian, in addition to the images mentioned above, there are often deadly images that are frequently used to describe lips and emphasize a person's inner emotions.

*За окном еще темно, а внутри вагона от тусклых лампочек у всех **лица синие, как у утопленников** [Национальный корпус русского языка] (It is still dark outside the window, and inside the carriage, because of the dim lights, everyone's faces are **blue**, **like those of drowned men** [Russian National Corpus]);*

*Однажды я подплыл к нему, с тревогой взглянул в белое, покачивающееся на воде лицо: шевельнулись **синие, как у мертвеца**, **губы** [Национальный корпус русского языка] (Once I swam up to him, looked anxiously at the white face swaying in the water: **lips**, **blue, like those of a dead man**, moved [Russian National Corpus]).*

## Conclusion

Our analysis of stable comparisons with a color component, which are often used in the Tatar and Russian languages, has led to the following conclusions.

The study shows that these comparisons, used as a means of describing and assessing the appearance and internal state of a person, are frequently found in the Tatar and Russian languages. Their active use in speech and their variety can be explained by the fact that in the environment of a person there are many objects of various colour.

In both languages, the most common colours used in comparisons are white and black. The white color reflects not only a person's appearance (hair, face, skin colour), but also the state of his/her mind (fear, anxiety, illness, etc.). In the Tatar language, this color is often used to describe purity.

Black is used to depict the color of hair, eyes, eyebrows and eyelashes. Since people with black eyes and black hair are often found among the Tatars, more comparisons with black are found in the Tatar language.

Blue and green are more common when depicting the color of eyes, less often they are used to describe lips, hands and feet, in order to show the inner experiences of a person.

The red component comparisons are used to describe the color, fullness and beauty of lips. In Russian comparisons, this color is found more often, since it is synonymous with "red" in the meaning "beautiful". The use of this color to describe noses, eyes, arms and legs emphasizes the negative attitude of the writer, or speaker.

Thus, when analyzing comparisons, firstly, the information about the object of comparison is given; secondly, the object or concept that is the standard for comparison is described. The feature, taken as the basis, is clearly expressed in the object of the comparison, therefore this sign is one of its characteristic features. The use of such comparisons in text or speech, on the one hand, names the color of the described object; on the other hand, this comparison is a signal of a positive / negative physical or psychological state of a person. The color of the ethyalon not only reveals the appearance, the color, describing a person, but also provides additional information.

Stable comparisons are a reliable object for studying the world linguistic image and a productive source for linguocultural studies, which reflect the worldview of the population, for in order to portray unfamiliar things, people almost always put it next to a similar object. Sometimes internal similarity also becomes the basis for comparison, that is, according to external features, two completely different objects or concepts coincide. It should be noted that almost always when comparing, a subjective assessment is given, a certain attitude is reflected, fixed in a language unit and an object comparable to it.

In many ways, a comparison creates a certain type of a person's image and situations.

Comparisons in the Tatar and Russian languages are characterized by similarities in the

lexical-thematic groups of images used to describe the external appearance of a person, which is explained by the universality of human nature and human thinking and, in turn, means that the understanding of the surrounding reality is described by monochromatic comparisons. The presence of specific national standards in comparisons of the two languages is associated with mythology, culture, history, literature of each nation, as well as with the individual vision of a person representing a certain nationality.

**References**


Gumbol'dt, W. (1985). *Iazyk i filosofiia kul'tury* [Language and Philosophy of Culture]. 450 p. Moscow, Progress. (In Russian)

Maslova, V. A. (2007). *Homolingualis v kul'ture: Monografiia* [Homolingualis in Culture: A Monograph]. 320 p. Moscow, Gnozis. (In Russian)

*Natsional'nyi korpus russkogo iazyka* [Russian National Corpus]. URL: https://ruscorpora.ru/new (accessed: 26.08.2021). (In Russian)

Potebnia, A. A. (1993). *Mysl' i iazyk* [Thought and Language]. 302 p. Kiev, SINTO. (In Russian)

Ramazanova, D. B. (2013). *Leksika na tatarskom iazyke, otnosiashchaiasia k cheloveku* [Tatar Vocabulary Related to a Person]. P. 364. Kazan', izdatel'stvo IYALI. (In Russian)

*Tatar teleneꞑ yazma korpusy* [Corpus of Written Tatar]. URL: https://www.corpus.tatar (accessed: 26.08.2021). (In Russian)

*Tolkovyi slovar' tatarskogo iazyka* [Explanatory Dictionary of the Tatar Language]. URL: http://suzlek.antat.ru (accessed: 26.08.2021). (In Tatar)

*Tolkovyi slovar' tatarskogo iazyka* (2005) [Explanatory Dictionary of the Tatar Language]. P. 848. Kazan', Dom pechati. (In Russian)

*Tolkovyi slovar' Ozhegova* [Ozhegov's Explanatory Dictionary]. URL: https://dic.academic.ru/contents.nsf/ogegova/ (accessed: 26.08.2021). (In Russian)

Zamaletdinov, R. R. (2004). *Tatarskaia kul'tura v iazykovom otrazhenii* [Tatar Culture in Linguistic Reflection]. Moscow, Gumanit. izdat. tsentr VLADOS; 239 p. Kazan', Magarif. (In Russian)


---

# КЕШЕНЕ БӘЯЛӘҮ ЧАРАСЫ БУЛАРАК “ТӨС” КОМПОНЕНТЛЫ ЧАГЫШТЫРУЛАР (ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕ МАТЕРИАЛЫНДА)


**Рәмзия Марс кызы Болгарова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
ramzija5@yandex.ru.

**Раушания Сәгъдәтҗан кызы Нурмөхәммәтова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
rsagadat@yandex.ru.



Мәкаләдә татар һәм рус телләрендәге төс компонентлы компаратив конструкцияләр чагыштырма аспектта тикшерелә.

Әлеге тикшеренүнең максаты – төс атамасы кергән чагыштыруларны кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау һәм бәяләү чарасы буларак өйрәнү. Татар теленең язма корпусыннан, рус теленең милли корпусыннан алынган мисаллар тикшеренү материаллары буларак файдаланылды. Төс компонентлы чагыштырулар кешеләрнең тышкы кыяфәтендәге табигый үзенчәлекләрне яки кешенең физик яки психологик халәтендәге тышкы билгеләрне тасвирлаганда кулланыла. Әлеге образлы сурәтләү чаралары чагыштырылучы предметның һәм образның нинди булуына карап, уңай яки тискәре образ тудырырга мөмкин.

Фәнни-тикшеренү эшенең нәзари һәм гамәли әһәмияте хезмәтнең төп нәтиҗәләрен татар һәм рус телләре лексикологиясе, лингвомәдәниятне өйрәнүгә юнәлдерелгән хезмәтләрдә файдалану мөмкинлеге белән билгеләнә.



**Төп төшенчәләр:** татар теле, рус теле, чагыштырулар, төс компоненты, кешенең тышкы кыяфәте.


## Кереш

Кешенең әйләнә-тирә дөнья турындагы барлык күзаллаулары аның аңында формалаша һәм алар күп очракта фикерләүнең ассоциатив характеры белән аңлатыла. Кеше образы – гомумтел дөнья сурәтендә дә, милли дөнья

сурәтендә дә төп образларның берсе. Шуңа күрә кешене сурәтләгән тотрыклы компаратив тел берәмлекләрен тикшерү аның телдә чагылыш тапкан образын тулысынча күз алдына китерергә ярдәм итә.

Әйтергә кирәк, кеше образы – милли дөньяны кабул итүнең бер чагылышы. Төрле мәдәният вәкилләре үз күзаллауларына ия, дөнья турындагы мәгълүматны үзләренчә кабул итә. В. Гумбольдт фикеренчә, “төрле телләр – бер үк әйбернең төрле исемнәре генә түгел, ә аларга төрлечә караш та ул” [Гумбольдт, 1985, б.154]. Шуңа күрә дөнья сурәте телдә бары тик милли-мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып кына тасвирланырга мөмкин.

А.А. Потебня билгеләп үткәнчә, “сүз ярдәмендә кеше үзенең аңында булган нәрсәләрне яңадан танып белә. Ул бер үк вакытта хаостан яңа дөнья да иҗат итә һәм бу дөньяның чикләрен киңәйтү өчен үзенең көчен арттыра” [Потебня, 1993, б. 302].

Тотрыклы чагыштырулар – татар һәм рус телләрендә актив кулланыла торган берәмлекләр. Алар образлы, тәэсирле сөйләм чаралары, күпчелек очракта сөйләүченең яки язучының хис-кичерешләрен үз эченә ала. Фразеологиянең төрле катламнарындагы кебек үк, чагыштыруларда да халыкның күпгасырлык тәҗрибәсе тупланган. Шулай ук чагыштырулар мәдәни ассоциацияләр, тел һәм мәдәни тәҗрибә белән дә бәйле була.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Татар теленең язма корпусыннан, рус теленең милли корпусыннан алынган мисаллар фәнни-тикшеренү эшенең материалы булып хезмәт итте.

Әлеге корпуслардан кешене тасвирлый торган төс компонентлы чагыштырулар кергән мисаллар тупланды, ике телдә дә иң еш кулланылучы *кебек, как*, шулай ук төс белән турыдан-туры бәйле *төсле* бәйләүче чаралары ярдәмендә төзелгән чагыштырулар тикшерелде.

Мәкаләдә фактик материалны анализлаганда, күзәтү, чагыштырма, тасвирлама һәм семантик анализ методлары кулланылды.

## Фикер алышу

Кешенең тышкы кыяфәте буенча билгеле бер күләмдә мәгълүмат алырга, аның милләтен, җенесен, яшен, шулай ук шәхси үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкин. Гомумән, кешенең тышкы кыяфәте, аларны сурәтләү үзенчәлекләре милли мәдәният турында да күп нәрсә сөйли. Гадәттә, кешене тасвирлаган вакытта һәрвакытта да уңай һәм тискәре бәяләмәләр кулланыла. Әлеге хезмәттә татар һәм рус телләрендәге “төс” компонентлы чагыштырулар кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау һәм бәяләү чарасы буларак анализланды.

Төсләр, кешенең тышкы кыяфәте һәм эчке дөньясы үзенчәлекләренә өстәмә характеристика бирү максатында, билгеле бер объект яки күренеш белән чагыштыруның нигезен тәшкил итә. Төрле мәдәният вәкилләре бер үк төсне, аларның әһәмиятенә карап, төрлечә кабул итә һәм бәяли.

Төсләр символикасы белән кеше аңы катламнары, халыкның тарихы, мәдәни-иҗтимагый тормышы арасында тирән бәйләнеш бар. Төсләр төрле мәгънәләр белдерергә, төрле хисләр уятырга һәм ассоциацияләр тудырырга сәләтле, шул рәвешле алар кешенең психик дөньясында аерым һәм үзенчәлекле үзгәрешләр барлыкка китерә. Төсләргә нисбәтле ассоциацияләр дөньяны шәхси, милли, дини һ.б. кабул итү үзенчәлекләре белән бәйләнгән. Кешеләр элек-электән төсләргә аерым игътибар биргәннәр, болар халыкның ышануларында, борынгы риваятьләрдә, халык авыз иҗаты әсәрләрендә, дини тәгълиматларда урын алган.

Төсләр семантикасының үзенчәлеге – күпмәгънәлелектә. Һәр төстә бик күп төрле мәгънәләр яшеренгән. Тотрыклы лексик берәмлекләрдә төс атамаларының нәкъ менә шул сыйфаты калкып чыга.

Фәнни тикшеренүдә татар һәм рус телләрендә тәңгәллекләре булган һәм еш кулланылган төс атамалары (татар телендә: *ак, кара, кызыл, яшел, зәңгәр*; рус телендә: *белый, черный, красный, зеленый, синий*) кергән чагыштыруларга төп игътибар бирелде.

Кешелек мәдәниятендә *ак* һәм *кара* иң борынгы төсләрдән санала. Татар һәм рус телләрендәге чагыштыруларда бу төс атамалары бик еш очрый, моны әлеге төсләрнең танып-белүдәге һәм мәдәни әһәмиятенә бәйләп аңлатырга мөмкин.

Ак төс.

АК I с. 1. 1) Кар, сөт төсендәге; киресе: кара.

2) Үз төсен югалткан, чал, чаларган, көмеш төсле.

3) Ялтырап торган көмешсыман төстәге, өстеннән никель йөгерткән.

4) Борчылудан, каушаудан, авырудан йөзе үзгәргән, төсе, чырае киткән, агарынган.

5) махс. Ике яки өч сүздән торган зоологик һәм биологик терминнарның (атамаларның) беренче кисәге.

6) күч. Чиста, керсез, пычранмаган, юылган (кием-салым турында).

7) күч. тар. Революциягә һәм Совет хөкүмәтенә каршы булган.

8) күч. Алдынгы; укымышлы, прогрессив.

9) күч. Язмыйча, буш калдырып, фикернең тәмамланмавына, яшерен эчке мәгънә булуына ишарә иткән [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге].

Б , -ая, -ое; бел, бела, бело и бело.

1. Цвета снега или мела.

2. полн. Светлый, в противоположность чему-н. более тёмному, именуемому чёрным.

3. полн. В первые годы гражданской войны: относящийся к вооружённой борьбе за восстановление законной власти в России.

4. белый, -ого, муж. То же, что белогвардеец.

5. полн. Со светлой кожей (как признак расы). Цветные и белые (сущ.) [Толковый словарь Ожегова].

Татар телендә “ак” компоненты кергән чагыштырулар кешенең тәнен, йөзен, тешләрен, кулларын, чәчләрен, сакал-мыекларын һ.б. тасвирлаганда актив кулланыла. Чагыштыру объекты буларак еш кына *кар, сөт, шикәр, мамык, аккош, шалкан, киндер* сүзләре кирә. Мәсәлән:

*– Иптәшләр, ишкәкләргә ныграк басыгыз! – дип пышылдый Искәндәр, һәм караңгыда аның **кар кебек ак тешләре** ялтырап китәләр* [Татар теленең язма корпусы];

*Йөзләренә таңның алсу төсе кунган, **шикәр кебек ак йөзле** Любаша аерылышуны үзенчә кичерде* [Татар теленең язма корпусы];

*Хәзрәт **мамык кебек ак**, йомшак **кулларын** биреп саубуллашты да җир өстендә йөзгән томан кебек, салмак кына атлап китеп барды* [Татар теленең язма корпусы];

*Көзгегә караганчы ук мин кулларымның **сабыйларныкы кебек ак** һәм җыерчыксыз булуын күрәм* [Татар теленең язма корпусы];

*Вәгъдәгөл карчыкны күргәч, Вера гаҗәпләнеп куйды: **башы кар кебек ак**, ник ичмасам бер кара чәче күренсен* [Татар теленең язма корпусы];

*Хәтта шәһәребезнең атаклы галиме, тарих фәннәре докторы Вәли ага үзе дә, куллары белән **кар кебек ак чигәләрен** кысып, бүлмәдә әрле-бирле йөренә һәм сөйләнә иде...* [Татар теленең язма корпусы];

*Картның **сөт кебек ак сакалы** калтыранып китте* [Татар теленең язма корпусы];

*Юк, ятим булмас аның әтисе кебек үк киң маңгайлы, зур кара күзле, **кызлар кебек ак йөзле**, озын керфекле улы* [Татар теленең язма корпусы];

***Тәне шалкан кебек ак** һәм тыгыз, җилкәләре киң иде Гафурның* [Татар теленең язма корпусы].

Югарыдагы мисалларда *кар, сөт, шикәр, мамык, сабый* һ.б. образлар уңай тәэсир тудыра.Әлеге эталоннар сүзлектә бирелгән аңлатмалар белән дә туры килә.

*Менә мин нишлим, менә ник **битем киндер кебек ак**, менә ник минем күзләрем тиле кешенеке кебек!* [Татар теленең язма корпусы];

*Нәрсә булды, **йөзең чүпрәк кебек ак**? – диде аңа тегесе* [Татар теленең язма корпусы].

Әлеге чагыштыруларда да ак төс кулланыла, тик *киндер, чүпрәк* образлары аша кешенең кыяфәтенә тискәре бәя бирелә.

Ак төснең кеше аңына эмоциональ тәэсире көчле, чөнки ул яктылык, көн, чисталык белән бәйле ассоциацияләр тудыра. Болар барысы да ак төснең уңай бәя бирүдә катнашуына нигез булып тора. Шуңа күрә “ак” компонентлы чагыштырулар ярдәмендә кеше күңеленең чисталыгы, сафлыгы да сурәтләнә. Бу чагыштырулар да кешегә уңай бәя бирү өчен кулланыла. Мәсәлән:

*Шул мизгелдә сине җиргә төшереп, теге **Хозыр Ильяс кебек ак Бабай**, елмаймыйнитми, китаплар артыннан килеп чыга һәм синең кулыңа озынлыгы ике метрдан да ким булмаган очлы таяк тоттыра* [Татар теленең язма корпусы];

*Зөбәйдә – **кар кебек ак**, су кебек пакь **кыз*** [Татар теленең язма корпусы];

***Ул** да бүген нәкъ шул **каен кебек ак** иде, биек иде һәм бәхетле иде, кичәге көнне кичәгесендә калдырып, бүген чиксез бәхетле иде* [Татар теленең язма корпусы].

Татар телендә *ак* сүзе, *көл, май* лексемалары белән бер сүзтезмәдә килеп, үзенчәлекле образ тудыруда катнаша. Мәсәлән:

*Кадермәтнең **йөзе көл кебек ак**, иреннәре күгәреп каткан...* [Татар теленең язма корпусы];

***Йомарлак май кебек ак тезләр**ен каплар-капламас чуар күлмәк...* [Татар теленең язма корпусы].

Бу чагыштырулар, контекстка карап, кешегә уңай бәя дә, тискәре бәя дә бирергә мөмкин.

Рус телендә “ак” компонентлы чагыштырулар да тән, йөз, чәч, сакал һ.б.ны сурәтләгәндә еш кулланыла. Рус теленең аңлатмалы сүзлегендә дә ак төс кар, акбур төсе белән чагыштырып аңлатыла. Шуңа күрә чагыштыру объекты буларак, шулай ук *кар, акбур, кәгазь, мамык, сөт, он, каен* һ.б. образлары киң таралыш алган. Мәсәлән:

*Его атласные* ***волосы, белые, как снег****, были расчесаны; он разглаживал седую бороду* [Национальный корпус русского языка];

*Подошёл* ***Василий*** *совсем близко: лица на нём нету,* ***белый, как мел****, глаза дикие; говорить начал – голос обрывается* [Национальный корпус русского языка];

*Нюрка стала реветь без слов, а* ***Володя, белый как бумага****, лепетал и точно боролся с кем-то, кто подшибал его под коленки, опрокидывал навзничь и душил* [Национальный корпус русского языка];

*Оксана обернулась – брат был* ***с лица белый как простыня*** *и белой же рукой указывал на что-то там, на земле* [Национальный корпус русского языка];

*Номер вполне мог стать смертельным, и* ***Виталий*** *действительно на миг потерял сознание, но все же опомнился и,* ***белый, как полотно****, самоотверженно довел до конца эпизод с канарейкой* [Национальный корпус русского языка];

*Бросила взгляд на Рапопорта –* ***он белый как скатерть*** [Национальный корпус русского языка].

Рус телендә *лунь, покойник, смерть* һ.б. сүзләре белән бер сүзтезмәдә кулланылып, үзенчәлекле образлар тудыру да еш очрый. Мәсәлән:

*Седые* ***волосы, белые как лунь****, бритое лицо – некрасивое, но интересное каждою морщинкой* [Национальный корпус русского языка];

***Фомич*** *сидел посреди дороги,* ***белый как покойник****, и еле дышал, убитый жарой* [Национальный корпус русского языка];

*Хмель из плотника вышибло, а рядом****,*** ***белый, как смерть****, стоял* ***шофер*** [Национальный корпус русского языка].

Кеше йөзенең аксыллыгы рус телендә үлем белән тиңләштерелә, *смерть, покойник* образлары аша кешенең тышкы кыяфәте генә түгел, физик халәте дә, эчке кичерешләре дә тасвирлана.

Мисалларда ике телдә кулланылган образларның лексик-тематик төркемнәре охшаш булуы ачык күренә. Татар һәм рус телләрендә “ак” компонентлы чагыштырулар кешенең чәчләрен (чал чәчләрне), тешләрен, тән төсен, шулай ук физик һәм эмоциональ халәтен (авыру, ару, борчылу, курку һ.б.) сурәтләү өчен кулланыла.

Кара төс.

КАРА I с. 1. 1) Корым төсендәге; иң караңгы төсле.

2) Куерак, караңгырак төстәге.

3) Караңгы; яктылык төшми торган, куе, калын.

4) Негроид расаның билгесе буларак, ак тәнлеләрдән нык аерылган караңгы төстәге.

5) Тумыштан каратутлы, чәче һәм тән төсе башкаларныкыннан караңгырак булган.

6) Кояш астында озак булудан, җылы якларда яшәүдән аклыгын югалткан, каралган, кояшта кызган (кешедә бит, тән төсе тур.).

7) Керле, пычрак, юынмаган.

8) Сөт кушылмаган (чәй, кофе һ.б.ш.).

9) иск. Махсус исерткеч итеп эшләнә торган (кымыз).

10) Морҗасыз, төтене махсус тишектән – төнлектән чыга торган (мунча, өй тур.).

11) иск. Хезмәтчеләр тора торган, кышын терлек-туар кертелә торган (өй, бүлмә тур.) [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге].

ЧЁРН , -ая, -ое; чёрен, черна, черно и чёрно.

1. Цвета сажи, угля.

2. полн. Тёмный, в противоп. чему-н. более светлому, именуемому белым.

3. Принявший тёмную окраску, потемневший.

4. полн. В старину: то же, что курной. Чёрная баня.

5. перен. Мрачный, безотрадный, тяжёлый.

6. полн., перен. Преступный, злостный.

7. полн. Не главный, задний (о входе, ходе).

8. полн. О труде: физически тяжёлый и неквалифицированный.

9. полн. Принадлежащий к непривилегированным, эксплуатируемым классам общества (устар.).

10. полн. На Руси в 1217 вв.: государственный, не частновладельческий.

11. полн. С тёмной кожей (как признак расы), чернокожий [Толковый словарь Ожегова].

Элек-электән кешеләр кара төсне төн, караңгылык белән бәйләгәннәр. Бу төс кеше аңында куркыныч ассоциацияләр барлыкка китергән. Шунлыктан әлеге төс кергән чагыштырулар ике телдә дә тискәре образ тудыра. Мәсәлән:

***Чырайлары корым сарган кебек кара** көйгән* [Татар теленең язма корпусы];

*Берни дә барып чыкмагач, **шайтан кебек кара йөзле**, сасы сарымсак белән тәмәке исе аңкытып торган урыс аны этә-төртә урамга куып чыгарды* [Татар теленең язма корпусы];

*Аннан таза гәүдәле, **сумала кебек кара чырайлы**, кысык күзле, чәче-кашы ат кылын хәтерләткән адәм күренде* [Татар теленең язма корпусы];

*Чырайлары чытык, **битләре кайрак кебек кара** янган* [Татар теленең язма корпусы];

*Совсем как этот: усатый, **черный, как головешка**, со злым лицом* [Национальный корпус русского языка];

*Иногда приходил **черный как туча**, вздрагивал от каждого шороха* [Национальный корпус русского языка];

*В центре группы на охапке сена возлежал **черный, как негр, детина** с одной ногой* [Национальный корпус русского языка];

***Арап** лежал в гробу в морском мундире времени Екатерины, **черный как уголь...*** [Национальный корпус русского языка];

Әлеге төс кергән чагыштыруларны ике телдә дә чәч, күз, каш, керфекләрне тасвирлаганда да күзәтергә мөмкин. Эталон буларак, *төн, сумала, күмер, җир, болыт, шомырт, карлыган, карга, карга канаты, гарәп, чегән* һ.б. сүзләр актив кулланыла. Мәсәлән:

***Күзләре** минекенә охшаган, **төн кебек кара*** [Татар теленең язма корпусы];

*Чигә **чәчең** кара иде, / **Сумала кебек кара*** [Татар теленең язма корпусы];

*Алланып торган кояш чыгышыннан китерелгән җитез егетнең **шомырт кебек кара күзләренә** кылдан нечкә итеп очланган инәләр кададылар, ди* [Татар теленең язма корпусы];

*Ул арада сигез-ун яшьлек яланаяк, яланбаш, үзләре **ком гарәбе кебек кара янган** ике **малай** килеп чыкты* [Татар теленең язма корпусы];

***Чегән кебек кара чәчле**, кара тәнле булганы өчен генә түгел, ә эшчеләр арасында иң яше булганга да, аңа шулай дип дәшәләр иде* [Татар теленең язма корпусы];

*Телефон баганасыдай озын, **мунча ташы кебек кара Хәниф** иде ул* [Татар теленең язма корпусы];

*Икенчесе егерме-егерме биш яшьләрдәге егет, ә яңакларында **кара урман кебек кара сакал*** [Татар теленең язма корпусы];

***Төн кебек кара**, ишелеп төшкән **чәчләрен** төзәтеп куйды* [Татар теленең язма корпусы];

***Күмер кебек кара чәчләре** арасында көмешсу көл сибелгән кебек* [Татар теленең язма корпусы];

*Аннан калын гына гәүдәле, тулы битле, кысыграк күзле бер кеше төште, **кашы, чәчләре сумала кебек кара*** [Татар теленең язма корпусы].

Рус телендә дә шул ук образлар еш очрый. Мәсәлән:

*Лица их были смуглые, носы приплюснутые и губы толстые, **глаза чёрные, как смоль**, равно как и волосы, висящие прядями, иные были с редкими бородами, иные же и вовсе без бород; в разные части лица были у них воткнуты длинные косточки и вставлены камешки* [Национальный корпус русского языка];

*И я, подчиняясь моему порыву, наклонилась к ней и нежно поцеловала ее **глаза, черные, как ночь**, и горящие, как алмазы* [Национальный корпус русского языка];

*Передок занимал квадратный, **черный как ворон мужик**...* [Национальный корпус русского языка];

*Лицо у него было смуглое, два черных глаза горели, как угли, не покрытые париком короткие **волосы, черные, как воронье крыло**, вились мелкими кольцами, и весь он был одет в черное* [Национальный корпус русского языка];

***Лёва** высокий, стройный, **чёрный, как цыган**, Олеся ему по плечо, белолицая русалочка с льняными волосами...* [Национальный корпус русского языка].

Әлеге төс ярдәмендә, чагыштырыла торган предметның һәм образның нинди булуына карап, уңай яки тискәре образ күзалланырга мөмкин.

Кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлаганда (чәч, күзләр, каш, керфек), кара төс еш кына уңай тәэсир калдырса, кешенең физик халәтен яки эчке кичерешләрен сурәтләгәндә тискәре образ тудыра.

Кызыл төс.

К З I с. 1. 1) Спектрның төп төсләреннән иң беренчесе төсле, кан төсендәге.

2) сөйл. оны, төкләре кызгылт көрән, куе җирән төсле (сыер, бозау төсе тур.).

3) Кызыл төс алган, беркадәр кан төсе кергән, кызарган.

4) тар. Октябрь революциясенә, революциядә катнашучыларга, большевикларга, революцион эшчәнлеккә бәйләнешле; Советлар Союзына, Кызыл Армиягә караган.

5) иск. тар. Җәдитчеләр хәрәкәтендә катнашучы, җәдитчелек тарафында булган.

6) күч. Һич тайпылмыйча билгеле бер карашны яклаучы, эзлекле тарафдар булган, ортодокс булган.

7) Ботаника, зоология, минералогия кебек фәннәрдәге кайбер тезмә терминнарның беренче компоненты буларак кулланыла.

8) Югары пробалы, саф (кыйммәтле металлар тур.).

9) Югары уку йортын «бик яхшы» билгеләре белән генә тәмамлаган студентларга бирелә торган (диплом тур.) [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге].

КРАСН , -ая, -ое; -сен, -сна, -сно и -сно.

1. (-сно). Цвета крови, спелых ягод земляники, яркого цветка мака.

2. полн. Относящийся к революционной деятельности, к советскому строю, к Красной Армии.

3. Употр. в народной речи и поэзии для обозначения чего-н. хорошего, яркого, светлого.

4. полн. Употр. для обозначения наиболее ценных пород, сортов чего-н. (спец.).

5. красный, -ого, муж. Сторонник или представитель большевиков, их революционной диктатуры, военнослужащий Красной Армии [Толковый словарь Ожегова].

Кызыл төс башка төсләр арасында үзенең яктылыгы һәм матурлыгы белән аерылып тора, әлеге төснең күчерелмә мәгънәләре дә күп. Күп кенә халыкларда ул изге төс булып та санала, еш кына кан, ут төсе белән бәйләп карала.

“Кызыл” компонентлы чагыштыруларда күп очракта эталон буларак, бакча һәм кыр чәчәкләре исемнәре (мәк чәчәге, чәчәк, гөлчәчәк һ.б.), җиләкләр, җиләк-җимеш, яшелчә исемнәре файдаланыла. Мәсәлән:

*Оятыннан **гөл кебек кызыл йөзе**, Ак киемнән, алтын таҗ кигән үзе* [Татар теленең язма корпусы];

*Кырысрак сыман күренгән хатын бала янында бөтенләй эреде, ул аны иркәли, **алма кебек кызыл битләреннән** үбә башлады* [Татар теленең язма корпусы];

*Ә анда, авызын ерып, **җиләк кебек кызыл чырайлы** Әнвәр абый бүрәнә юнып маташа иде* [Татар теленең язма корпусы];

*Кызый чибәр, аның карлыгандай кара күзләренә, **чия төсле кызыл иреннәренә**, алма кебек тыгыз, түгәрәк күкрәкләренә сокланып карап тормыйча түзеп булмый* [Татар теленең язма корпусы];

***Йөзе чөгендер кебек кызыл** иде* [Татар теленең язма корпусы].

Рус телендә әлеге төркемгә караган чагыштыруларда чәчәк, җиләк-җимеш, яшелчә исемнәреннән тыш, хайван исемнәре, ут-ялкын образлары да еш очрый, бу төснең метафорик мәгънәләре дә күбрәк. Мәсәлән:

Ф. Дәүләтшин «Нурия бәете»н үзенең иң күренекле әсәрләренең берсе дип исәпли. «Ул бәет белән мин халык арасында танылу алдым. Мине хәтта чит районнарга да махсус бәет сөйләргә чакыра башладылар», – дип яза чичән үзенең автобиографиясендә [Давлетшин]. «Фәррах чичәннең иң күренекле әсәрләренең берсе – «Нурия бәете» тормышта булган вакыйгадан алып язылган. Шулай булуга карамастан, аның гомумиләштерелгән мәгънәсе бик зур. Бәет персонажларының берсе Сания, мәсәлән, Нуриянең югалткан балдагын кеше гомереннән дә өстен куя. Әйбергә, байлыкка табыну аны кешелеклелек сыйфатларыннан бөтенләйгә мәхрүм итә. Нәтиҗәдә Нурия Сания мәрхәмәтсезлегенең корбанына әйләнә. «Нурия бәете» – фаҗигале әсәр, ләкин аның фаҗигасе укучыны кеше булырга чакыра торганнардан», – дип яза галим, әдәбият белгече, тәнкыйтьче Ким Әхмәтҗанов [Сәсән тауышы, 3-8 б.].

1930 елда Казанга баруы турында сукыр Фәррахның аерым әсәре бар. Ул «Фәррахның Казанга барган юллары» дип атала. Чичән әсәрләрен алып, бер тиен акчасыз юлга чыга. Сукыр кеше берьялгызы, җәяүләп, Казанга бара. Халыкка бәетләр сөйли-сөйли, тамак туйдырып, авылларда куна-куна, Дүртөйле, Югары Яркәйне үтеп, Минзәләгә җитә. Шәһәр базарында үзенә юлдаш таба. Икәүләп Чаллыга барып җитәләр. Бер кешегә ялланып, утын яралар. Теге адәм боларны алдый, тиешле акчасын түләми. Шуннан алар аның бакчасындагы бәрәңгесен казып алып ашыйлар. Алабуга, Мамадышны үтеп, Казанга барып җитәләр, шунда ул юлдашыннан аерыла. Фәррах Дәүләтшин күренекле татар язучысы Нәкый Исәнбәтнең фатирын эзләп таба.

«Мамадышны үтеп киткәч, ерак түгел Казан да,

Казаннарга барып кергәч, йөримен базар-ларда.

Иптәшем китте уң белән, үзем киттем сул белән,

Исәнбәтне эзләп таптым, трамвайский юл белән», –

дип яза ул.

Нәкый Исәнбәт аны яхшы каршы ала, ихлас сөйләшә. Фәррах аларда бер кич кунып, иртән Матбугат йортына бара, әмма уңышсызлыкка очрый: анда аның кульязмаларын алып кала-лар, ләкин китап итеп чыгармыйлар.

«Фәррах Дәүләтшин, Сәет Исмәгыйлев, Мөхәмәтша Бурангулов кебек әдипләрнең әсәр-ләре язма әдәбиятка карыймы, әллә фольклорга керәме, дигән мәсьәлә буенча вакытында бәхәсләр дә булып алган иде. Бу – әдәбиятта махсус проблема. Монда фәкать шуны гына әйтергә була: аларның берсе дә хәзерге мәгънәдәге шигырь түгел, республика хөкүмәте тарафыннан бирелгән «халык чәчәне» дигән исем аларның поэтик эшчәнлеген бик дөрес гәүдәләндерә», – дип саный К. Әхмәтҗанов. «Фәррах Дәүләтшин иҗатына, башлыча, бәет формасы хас. Шунысы кызыклы: стиль һәм строфика җәһәтеннән төрле-төрле булсалар да, бу өч чичәннең күпчелек әсәрләре, жанр булу ягыннан шигырьгә якын торалар. Революциягә кадәр халык иҗатының шигырь дигән жанрны белмәвен искә алганда, чичәннәр иҗатындагы яңалыкларны ныграк аңларга мөмкин.

Фәррах Дәүләтшин иҗатында да яңа поэтик күренешләр байтак. Башкорт фольклорының жанрларын баету һәм төрләндерү өлкәсендә чичәннең күзгә күренерлек хезмәте бар. Кайчандыр кайгы-хәсрәтне чагылдыручы бәет жанрын ул, асылда, одаларга тартым мотивлар белән сугарды. «Чкалов бәете», «Галия кыз

бәете», «Ватан сугышы бәете», «Стаханов турында» кебек әсәрләрдә бәет поэтикасы аша алдынгы кешеләрнең портреты бирелә. «Талип», «Янгир абзый», «Габдрахман» кебек әсәрләрдә чәчән катлаулы иҗтимагый күренешләрне гомум сүзләр аша түгел, ә аерым кешеләр язмышына бәйләп сурәтләү осталыгын күрсәтте. Язма әдәбиятка гына хас булган пародия, эпиграмма кебек жанрларда да көчен сынап карады. «Ялкау», «Чалмалылар», «Гыймай бай», «Алты ялкау бәете» исемле шигырьләрдә юмор һәм сатираның һәйбәт үрнәкләрен бирде.

Күп кенә бәет һәм шигырьләрендә Фәррах бер үк строфадагы юлларның иҗекләр саны да төрлечә итеп бирә. Моның белән ул аерым сүз һәм җөмләләргә ныграк басым ясый ала» [Сәсән тауышы, 3-8 б.].

Фәррах Дәүләтшинның җырлары һәм бәетләре китапларга тупланып (1938 елда – «Орденлы халыҡ йырсыһы Фәррах йырҙары һәм бәйеттәре» [Йырҙар һәм бәйеттер], 1947 елда – «Чәчәннең киңәшләре» [Сәсәндең кәңәштәре], 1967 елда – «Чәчән тавышы» [Сәсән тауышы]), зур тиражлар белән бастырып таратыла, ә кайбер әсәрләре, рус теленә тәрҗемә ителеп, үзәк журналларда, альманахларда басыла. Аның иҗаты Башкортстан мәктәпләрендә, педагогия институтларында өйрәнелә.

Чичән иҗатының иҗтимагый, сәяси һәм сәнгати әһәмиятен искә алып, 1944 елның 14 апрелендә Башкорт АССРы Югары Советы Президиумы указы белән Фәррах Дәүләтшин «Башкорт АССРының Халык чәчәне» дигән мактаулы исемгә лаек була [Указ Президиума Верховного Совета Башкирской АССР].

Кызганыч, М. Воронцов үзенең мәкаләсендә Нәкый Исәнбәт исемен телгә алмый, галимнең эшчәнлеген – сукыр Фәррах җырларын язган “местный грамотей” дип бәяли [Воронцов, б. 48]. Бу “хәтерсезлекнең” тамырларын Нәкый Исәнбәт биографиясендә эзләргә кирәк. М. Воронцовның татар галименең исемен, “җидегәнче” исемлегендә булуы сәбәпле, телгә алмавы мөмкин. 1931 елның 7 февралендә Казанда Г. Кутуй, Н. Исәнбәт, Т. Ченәкәй һәм Г. Минский кулга алыналар. Аларны контрреволюцион оешма төзүдә гаеплиләр. 8 ай буена барган тикшерү көпчәккә терәлә. Г. Минский белән Н. Исәнбәтне 15 апрельдә (“чыгып китмәү турында кул куйдыртып”) азат итәләр. Г. Кутуй белән Т. Ченәкәйне 16 сентябрьдә, дәлилләр җитмәү сәбәпле, прокуратура ирекккә чыгара. “Хәтерсезлекнең” икенче сәбәбе дә булырга мөмкин. 1930 елда Нәкый Исәнбәт Уфадан Казанга яшәргә дип күчеп килә. Башкорт галимнәре Н. Исәнбәт безнең төбәктә җыйган халык иҗаты материалларын татар фольклористикасына бүләк итте дип “үпкәлиләр”. Галимнең архивында аның 1928 елда СССР Фәннәр Академиясе Башкорт экспедициясенең тел һәм фольклор отрядында фәнни хезмәткәр булуы турында таныклык саклана.

Татар галиме бер радиоинтервьюда үзенең фәнни һәм әдәби эшчәнлегендә халык авыз иҗатының тоткан урынын һәм аны өйрәнү тарихын шулай билгели: «Илле ел буена төрле шигырьләр, драмалар һәм башка әсәрләр язуым белән бергә, бу халык иҗатын җыю һәм өйрәнүне дә бервакытта да ташламадым. Фольклорны мин әлегәчә күпләп бастырып чыгара алганым юк. Ләкин алар миндә бик күп хәзер.

Мин халык авыз иҗатын иң элек үзен бик яратам, аңа бик зур бәя бирәм. Шуның өстенә аны белүем минем язучылык эшемдә һәрвакыт ярдәм итә” [Исәнбәт. Минем язучы булуым һәм халык иҗатын өйрәнүем].

Н. Исәнбәт борынгы татар шагыйрьләренең һәм хакимнәренең чәчән/чичән дип аталуларын һәм аларның кабилә-кавем тормышында зур роль уйнауларын борынгы дастаннардан, мәкальләрдән һәм тарихи чыганаклардан күп фактлар китереп дәлилли. «Мәкальләребез турында» исемле хезмәтендә галим *чичән* сүзенә шундый аңлатма бирә: «Чичән дип аталган кеше хәзер бездә үзе түгел, хәтта сүзнең үзе дә, кулланудан төшеп, авыз иҗтында гына калып бара. Х. Бәдигь мәкальләр җыентыгының 1912 елгы басмасында *чичән* сүзенә «пөхтә, көяз, фырт» дип аңлатма бирә, тик 1926 елгы басмасында гына «сүз остасы» дип дөресли.

Китабының һәр ике басмасында хәтта чечән дип язылган. Бу сүзнең халыкка сүз остасы мәгънәсендә йөрүе билгеле. Ул бик телгә чичән кеше, диләр. Кайбер сөйләшләрдә чәчән формасын да кулланалар. Казахларда – шешен, башкортларда сәсән йөри. Соңгыларда шул исемдә әдәби, рәсемле бер журнал да чыгарылды, һәм тоткарсыз рәвештә җыр чыгарып әйтә алучы берничә халык шагыйренә сәсән исеме бирелде. Монысы безнең өчен тагын да әһәмиятле. Чөнки монысында чичән сүзенең матур сөйли белүче генә түгел, илһами рәвештә, кәгазьгә язмастан, тоткарсыз шигырь әйтүче шагыйрь-импровизатор мәгънәсен дә үз эченә алуын күрсәтә. Һәм ул тарихлар буенча шулай да. “Чичән” сүзе элек сүз остасы дигәнне дә, җыручы-импровизатор дигән мәгънәне дә

аңлаткан. Димәк, ул һәр ике профессияне үзендә бергә җыйган кеше, борынгы халык шагыйре дигән сүз» [Татар халык мәкальләре, б. 41 – 42].

Н. Исәнбәт халык арасында киң кулланылышта йөргән мәкальләр, фразеологик гыйбарәләр, дастаннарны анализлау нигезендә чичәннәрнең борынгыдан бирле җәмгыятьтә тоткан урыннарын билгели, импровизатор шагыйрьләрнең халык арасында алыштыргысыз абруе булганлыгын исбат итә: «Бездә дә чичән дигән исемдә зур хөрмәтле халык кешеләре булуы татар мәкальләренең үзләреннән үк күренеп тора: *Батыр яуда беленер, чичән дауда беленер.* Димәк, батырлар ил чигеннән килгән яуны бетерүдә беленсәләр, чичәннәрнең телгә осталыгы да ил эчендәге дауларны (конфликтларны) бетергәндә беленә. *Чичәннең теле уртак, чибәрнең кулы уртак.* Моннан чичәннең сүзе мәгънә һәм хикмәткә, димәк ки, уртак әһәмияткә ия булуы, шуның белән халыкка уртак булуы әйтелә. Аның бу осталыгы эштә һөнәрле кешенең кулына чагыштырыла. Шулай ук борынгы халык дастаннарына караганда, чичәннәрнең сынчы (сынаучы – алдан хәбәр итүче) булулары да бик ачык күренә. Мәсәлән, кабилә һәм феодаллык тормышында кайбер кешенең кемлеген сынап белергә хаҗәт төшә. Моны белү ул заманда бик җиңел булмаган. Бигрәк тә дәүләт тирәсендәге кешеләрнең хокук дәрәҗәләре аның асылы-нәселе кем булуга бәйләнгәнлектән, бу белгечлек аеруча әһәмият казана. Шундый сәләт һәм осталык сорый торган бу эш сынчылык дип аталган. (Бу сүзне хәзерге сынлы сәнгать белән бутарга ярамый.) Сынчылар кешенең йөзенә, кыланышына бераз гына карап торгач та, читләтеп, бер-ике сорау белән аның нәселен, чыгышын, үзенең кемлеген, киләчәк язмышын әйтеп бирергә тиеш булганнар. Пәйгамбәрлек итү шикелле мондый серле-хикмәтле эшнең дә чичәннәр тарафыннан башкарылуы безнең өчен бик әһәмиятле. Мәсәлән, дастаннардан күренгәнчә, олы хан, үзенә җибәрелгән бер илченең кем икәнен ачу өчен, кайдадыр халык арасында яшәгән шундый бер өлкән җырчы чичәнне чакырта. Бу чичәннең яше ике йөзләргә җиткән карт булуы (ягъни тормышта күпне күргән, кешеләрне күп сынаган, бай тәҗрибәгә ия булган образ), кат-кат чакыртып та, бик ялындырып, алтын арбада мамык түшәкләр өстендә генә килүе, гаять дәрәҗәдә мәһабәтлеге, ул мәҗлес түрендә беренче урынга утырып, олы хан үзе аның каршында аякчы (савыт-саба биреп торучы; касә сонучы, шәрабче. – *асс. М. Х.*) булып, кулыннан бал бирүләре бик тәэсирле сурәтләнгән. Ул үзен олы хан алдында бөтенләй иркен, бәйсез тота. Аның үтенечен теләр-теләмәс кенә кабул иткәч, шунда утырган илчене үзенә сиздермичә сыный башлый, югарыда әйтелгәнчә, аңа җиңел генә бер йомыш үтәргә куша, читләтеп кенә, берәр сорау бирә. Йөзенә, кыланышына текәлеп караганнан соң, думбрасын кулына алып, бу әйтелгән илченең үткәнен һәм киләчәген әйтеп, кемлеген ача башлый. Шунысы кызык: ярым көйләп уку, ярым җыр шикелле тезелгән бу сүзләр мәкаль һәм шигъри образларга бай тезмәләрдән тора.

Без мәкальләрнең килеп чыгулары, бер яктан, борынгы сынау, тәҗрибә һәм хәтта күрәзәлекләр белән бәйле булганын күргән идек. Монда аның нәкъ шул хасияте җыручы чичән тарафыннан сынауга тотылганын күрәбез, ягъни мәкаль үзе сынаудан туса, аны мәгълүм тәртипләрдә тезә белү һәм шул алымда үзеңнән дә образлы сүзләр куша белү аша сынчылык итеп була дип уйлаган борынгылар кемнең кемлеген дә мәкальчелек белән сынап, ачып була дип эш иткәннәр. Шул сәбәпле без борынгы заманнарда мәкаль һәм аны барлыкка китерү сәләтенең югары бәяләнгәнен, мәкаль ул яшерен, серле, хикмәтле көчләргә ия, мондый алым белән эш итә белүче кеше хәтта ки пәйгамбәр дәрәҗәсендә гамәлләр кыла ала дип каралганын күрәбез. Бу яклары белән чичән борынгы грекларның оракулына, мисырлыларның жрецына, гарәпләрнең шәехенә, каһиненә, бездәге багучы, баксы, бәхши, күрәзә, шаман һәм сынчыларга якын тора. Бу җәһәттән без борынгы кабилә тормышы катлауланып, аксакаллар һәм шаманнар инде халыкның тел, тәҗрибә һәм хикмәт байлыгын, авыз иҗатын үзләренә туплап бетерә алмагач, идея һәм сәнгать өлкәсен шул эшнең аерым осталары булган шагыйрь-чичәннәргә тапшыра башлаулары ихтимал дигән фикердә торабыз.

Билгеле, мондый җыручыларга һәм хакимчичәннәргә борынгылар тәҗрибә һәм хикмәтнең сихри көченә ия дип караганнар, шунлыктан аларның исемнәре алдында ханнар да куркып торган һәм чичәннәрнең күңелләрен яулап, алар аша хакимлек җепләрен җәяргә, халык арасында үз дәрәҗәләрен күтәрергә тырышканнар. Ләкин тарихтан билгеле булганча һәм югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, халык шагыйре һәм хакиме булган чичәннәр үз профессияләренә бик зур бәя биргәннәр, тәхет алдында үзләрен вак тотмаган кебек, халык

күтәрелешләре вакытында аларның хәрәкәт башында торган чаклары да булган. Мондый очракта аларның тел-иҗат куәте реаль көчкә әйләнгәнгә, ханнар өчен бу җитди куркыныч тудырган. Мәсәлән, шундыйлардан Җамукай чичәннең найманнар күтәрелеше башында торуы һәм, үзенең тел кылычын Чыңгыз кылычына каршы куеп, утыз еллар буе аңар баш бирмичә, күтәрелеш алып баруы билгеле.

Кытай тарихыннан мәгълүм булганча, с а с а н ы г дип (чичән, чәчән, сәсән) аталган кешеләр төрки кавем-кабиләләрнең вәкилләре арасында борын-борыннан очрый һәм халыкның иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрендә дә аларның билгеле эз калдырулары күренә. Шулай итеп, бу сүз үз авызыннан шигырь-хикмәт чәчә белүче чәчәнме, әллә мәсьәлә чишә белүче хаким мәгънәсендә чичәнме, ул хәтлесен белеп булмый. Ләкин бу сүзнең Кытайдан алып, безнең ошбу җирләргә хәтле таралып яшәгән һәммә төрки халыкларда очравы борынгы кавем-кабиләчелек һәм патриархальлек заманнарында мондый жанр иҗатның һәммәсендә дә нык таралган булуын күрсәтә» [Татар халык мәкальләре, б. 42 – 43].

Н. Исәнбәт үзенең мәкаләсендә чичәннәрнең иҗади эшчәнлеген җентекләп тасвирлый: «Чичән, җыручы буларак, ничек иҗат итә соң? Безгә монда аның шунысын белү әһәмиятле. Дөрес, ул безнең борынгы шагыйрь, ләкин ул бу замандагы шагыйрьгә бик аз охшаган. Иң элек ул шигырьне язып чыгармый, сөйләп тә чыгармый, аның кулында думбра, ул шуның кылларында күтәренке, ярым көйле авазлар белән безгә тоткарсыз тезмә чыгарып сөйли. Ул илһами әйтә белүче импровизатор, дидек. Бу һөнәргә ул ничек ирешә соң? Иң элек ул язусыз, хәтердән генә эш иткәнгә, аның хәтерендә фольклор һәм сүз алымнарының запасы бик зур. Ул борынгы халык җыр дастаннарының күбесен күңелдән әйтә, аларның шигъри алымнарын, сюжет һәм мотивларының һәр очракта ничек сайланышын, төзелеш, композициядәге йолаларын алдан ук белә. Гомумән, сөйләү теленең остасы буларак, борынгы телне сурәтле ясый торган бөтен чараларны – канатлы сүз, әйтемнәрне, фразеологияләрне, бигрәк тә мәкальләрне күп белә. Аның шигырь-дастаннарны тоткарсыз сөйли алу һәм тирән хикмәтле итеп чыгара белүенең тагын төп сере дә шул запаска ия булуында. Мәкальләр, ритмга һәм рифмага бай булулары сәбәпле, дастан шигъри формаларында төп тукымалар яки әзер кәрәзләр булып хезмәт итәләр, шулар буенча чичән балавызны теләгән якка теләгәнчә суза. Шуның белән безнең ул борынгы шагыйрь-чичәнебез, аркасына думбрасын аскан хәлдә, авыл-шәһәрләр аша бик иркен гизә; кайда тагын шундый бер шагыйрь барын ишетсә, анда барып, мәҗлестә аның белән ярышка керә, кара-каршы хикмәт, шигырь әйтешеп җиңешә. Мәкальләрнең кагыйдәчел, дәлилле һәм мисаллы булулары чичәнгә хөкем тәртипләренә катышырга да мөмкинлек бирә. Шуның өчен дә чичән ул туй-мәҗлесләр түрендә генә түгел, ил эчендә барган дау-ызгышларны хәл итешүгә дә чакырып китерелә. Менә ни өчен ул даудa беленә!» [Татар халык мәкальләре, б. 43 – 44].

Чичәннәр иҗатының стиль үзенчәлекләрен анализлап, Н. Исәнбәт импровизатор шагыйрьләрнең мәкальләргә еш мөрәҗәгать итүенә игътибар итә: «Шул рәвешле, чичән – халык шагыйре һәм хаким кеше. Шагыйрь буларак, ул җыр, эпос-дастан тудырса, хаким буларак, ул тирән мәгънәле шигырь, хикмәтле сүз әйтә. Моның өчен ул борынгы мәкальләр алымыннан бик нык файдалана. Ул искиткеч күп мәкаль белә. Жанрның төзелеш һәм ритм йолалыгын (традицияләрен. – *асс. Н. И.*) бик нык үзләштергәнлектән, бу алым белән тоткарсыз иҗат (импровизация. – *асс. Н. И.*) теземнәре әйтү аңа җиңел дә, табигый дә. Шуның белән ул берише мәкальләрне төзек бер композициядә тезеп, дастан сюжетын куәтле дәлил һәм конфликт мотивларына әверелдерә. Билгеле, ул мәкальләрне, тышкы охшашлыкларына карап, механик рәвештә генә төземи, бәлки, шагыйрь һәм хаким буларак, үзе дә шул типта мәкальләр ясый, алар белән теземне цементлап, бөтен бер фикер һәм хис әсәренә әйләндерә. Шуның белән мәкальләрдән үзенә яңа бер төр фольклор жанры килеп чыга. Дастаннардан күренгәнчә, моны сарын (сарнап яки мәкальләрне бер-берсенә сарып, күтәренке бер тавыш белән әйтү. – *асс. Н. И.*) яки тулгау, диләр. (Яки туглау, әйтик, каймакны туглап язып, май төшереп булган кебек, берише мәкальләрдән туглап, олы бер фикер чыгару була. - *асс. Н. И.*) Башкортлар моны кобаер әйтү, диләр.

Шулай булгач, бу инде мәкальләрнең очраклы теземе генә түгел, бәлки, аларны билгеле бер юнәлештә сару юлы белән хикмәт сөземтәсе чыгару нәтиҗәсендә, тагын да тирәнрәк мәгънәле, яңа сыйфатлы, көчле бер яңа жанр тудыру дигән сүз» [Татар халык мәкальләре, б. 44].

Энциклопедик галим үзенең хезмәтендә Алтын Урда дәверендәге генә түгел, ә XIX гасырда Казан артында яшәгән чичән-шагыйрьләрнең дә исемнәрен атап үтә: «Соңга табарак шагыйрьлек һәм тел осталыгы сәләте тагын икегә аерылып, чичән сүзенең мәгънәсе сөйләү теленең осталыгына кайтып калган; ул мәҗлесләр тотучы, даулар хәл итүче, сүзгә тапкыр, үткен телле оратор мәгънәләрен эченә җыйган. Шулай булса да, думбра кыллары астында, аларның ярым сөйләү, ярым көйләү юлы белән сарнап, тоткарсыз шигырь- хикмәт тудыра алу йоласы күчмә кабилә халык шагыйрьләрендә әле дә калган. Казах, кыргыз халык шагыйрьләре, әйтик, Җамбул, Туктаголлар бүгенге көндә дә шул юл белән иҗат итеп килделәр. Алар инде чичән дип тә, шагыйрь дип тә түгел, акын дип аталалар. Акын, Радлов аңлатуынча, шул ук хаким дигән сүздән алынган. Бу дөрес булса, димәк ки, бу сүздә шигырь белән хикмәт аерылмаган, шагыйрь дә, хикмәт иясе дә була, ягъни ул да чичән дигән сүз. Шул рәвешле чичәндә без шигырь белән хикмәтне бергә килеш, синкретизм хәлендә табабыз. Бездә дә бу йола шушы йөз башларына хәтле бетеп җитмәгән. Мәсәлән, Казан артының Мәңгәр татары Сабирҗан акын һәм Лаеш ягындагы Байчыга авылының Байчыгави акыннар, шулай ук шагыйрь Акмуллалар шушы XIX йөз ахырларында гына казах арасына китеп, аларның акыннары белән тоткарсыз ярышта тудырган әсәрләре бу думбра кылы астында җырлап-сөйләп шигырь-хикмәт әйтү йоласының бездәге язма шигырь көнендә дә үзенә сукмак салып килүен күрсәтәләр. Акмулла: «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән», – дигәндә, шигырь белән хикмәтне аерымсыз каравын әйткән булса, үзе дә, шагыйрьлек һәм хакимлекне бергә җыйган борынгы чичән сыйфатында алга басып, шигырьне язып та, тоткарсыз сөйләп тә чыгара белү сәләтен күрсәткән кеше. Шул ук Акмулла алымнары белән әсәрләр тудырган Мәҗит Гафуриның баштарак язган «Себер тимер юлы» яки бигрәк тә «Яшь гомерем» дигән әсәрләре алып каралса, аның да казах акыннарының шигырь-хикмәт йоласына ия булганын күрәбез. Гафури соңрак, белмим, Тукай тәэсире астына төшепме, ни өчендер бу юлдан баш тарткан, әмма Тукай аның нәкъ шул акыннар алымы белән язган «Яшь гомерем»енә зур бәя бирә. Гафуриның ул әсәрләре, Акмулланыкы кебек үк, мәкаль һәм афоризмнарга бай булулары, ничек итеп шигырь тезмәсендә хикмәтне файдаланып, активлаштыруның, шагыйрьлек белән хакимлекне бергә җыюга омтылуның үрнәге булып тора. Тик монда безнең бу соңгы хаким-шагыйрьләрнең борынгы чичәннәрчә турыдан-туры ирекле мәкаль тезмәчелеге һәм дастанчылык алымнарыннан аерыла төшеп, унбер-унике иҗекле казах өләңчелеге тезмәсен файдалануларын әйтергә кирәк» [Татар халык мәкальләре, б. 46].

Нәкый Исәнбәт үзенең “Татар халык мәкальләре” җыентыгында “Сәнгатьле сөйләм осталары, чичәннәр, абызлар, ораторлар” темасына караган 30 мәкаль китерә, ул аны аерым параграф итеп формалаштырып бирә [Исәнбәт, Татар халык мәкальләре, б. 333 – 334 б.].

«Татар халкы эпосы – “Идегәй” дастанының биш йөз еллыгына» дигән фәнни мәкаләдә нәфис сүз осталарына түбәндәге характеристиканы бирә: «Инде дастан шикелле бөек халык иҗатларының ничек башкарылуына килсәк, алар зур осталык һәм игътибар таләп иткәннәр, борынгырак заманда алар профессиональ халык җырчылары (җыраулар. – *асс. Н. И.*) һәм тел остасы чичәннәр тарафыннан думбра, дутар, кубыз яки саз шикелле музыка кораллары ярдәме белән башкарылганнар» [Идегәй, б. 82]. “Идегәй”нең җыелма текстына шәрехләмәсендә Н. Исәнбәт түбәндәгеләрне яза: «Чичән – тел остасы, оратор. Татар тарихында дәүләт күләмендә эш иткән чичәннәрдән Чыңгызга каршы чыккан Җамукай чичән, Алтын Урдада Җанбик хан чорында яшәгән Җирәнчә чичәннәр билгеле» [Идегәй, б. 61].

Халык чичәненең күркәм образы дастанда һәм Н. Исәнбәтнең шул исемдәге трагедиясендә тудырыла. Ул - Субра карт:

«Кондыздай теше саргайган,
Азулар теше бушаган,
Йөз туксан биш яшәгән
Сыпыра санлы ерау бар,
Үзендә утыз ханның гомере бар,
Берсә - белмәсә бу эшне
Субра белер бу эшне» [Идегәй, б. 57 – 58 б.]

Фольклорчы әлеге герой исеменең килеп чыгышын болай аңлата: «Сыпыра сынлы – Вәлихановның 1841дә җыйган каракалпак вариантында аңлатмасында бу сүз – саф серебүче, ягъни бөтен тырнак астындагын ачып, барын да сыпырып бер-бер артлы сөйләп бирүче – дип аңлатылган. Безнеңчә – вариантларда күренгән Сыпыра, Субра, Сабра, Сафардау – сүзләре бар да бер бәйләнештә булса кирәк. «Суп», «сыбырдак» сүзләренең гүзәл, матур дигән мәгънәләре бар. Мәсәлән,

Себердәге бараба татарлары кияү егетен кыз катына япканда:

Сыбырдак буйлы яшь егет

Җилеп инәр, яр, яр, –

дип ерлыйлар. Биредәге «Сыбырдак» сүзе белән шул ук бараба татарларыннан Радлов тарафыннан җыелган Идегәй вариантында бу ерчының «Сафардау», «Сафардак» дип аталуы арасында бәйләнеш бар шикелле. Ягъни «Субра», «Субрау» исеме «Суп – ерау» – гүзәл ерчы мәгънәсендә әйтелгән булырга тиеш. Чөнки Березинның төрекмән варианты дип бастырган Идегәй дастанында без бу ерчының исемен "Хубра" рәвешендә күрәбез. Бусы «Хуберау» сүзенә кайта торган булса, һаман да гүзәл ерчы мәгънәсендә халык ерчысының кушаматы килеп чыга. Алда күрелүенчә, нугай, каракалпак һәм татар вариантларында сакланган:

Суп аяклы, суп бүрекле,

Сыпыра сынлы суп ерау, -

сүзе белән шул фикерләребезне дөресли. Инде Сабрау, Сафардау исемнәре Сәфәрдак яки Фәрәздакдан бозылган булса, бусыннан гарәп классик шагыйре Фәрәздәк исеме килеп чыга. Безнеңчә, бу исемнең гарәп классик шагыйренә һич бәйләнеше юк» [Идегәй, б. 57-58].

Фольклорчы Ф. Урманче күзәтүләренә караганда, дастанның Субра җырауга багышланган бүлеге – "сәнгати яктан гына түгел, ә сюжет үстерелешендә дә риваятьнең иң яхшы бүлекләренең берсе". [Урманче Ф., с. 66]. Н. Исәнбәтнең "Идегәй" җыелма текстындагы геройга – 195 яшь. Ул "күпне күргән күрәзәче карт кына түгел, ә гадәттән тыш зиһенле һәм тәҗрибәле җырчы". Бернинди магик гамәлләр, шаманлык, сихерчелек кылмыйча, магик китапларга мөрәҗәгать итмичә, бары тик күзәтүләр нәтиҗәсендә ул Кобогылның кем иканлегенә төшенә" [Урманче Ф., с. 66]. Субра картның пәйгамбәрлеге, Ф. Урманче фикеренчә, формасы ягыннан акыннарның бер иҗат төре булган толгауны – уйлануны хәтерләтә. Формасы ягыннан афоризмнарга якын шигъри юллар тыңлаучыларның игътибарын шунда ук җәлеп итә. Герой үзе дә борынгы чичәннәр традицияләренә таянуын яшерми. Субра карт Җанбайны, Идегәйне һәм Туктамышны ата-бабалар тарихын белү-белмәүләрен, эпик кыйссалар геройларына хас сыйфатларга (кыюлык, тәвәккәллек, зирәклек, үз-үзеңә ышанганлык, зиһенлелек) ия булу-булмауларын тикшереп карый.

Субра карт үзенең җырында Алтын Урданың рәсми сәяси тарихын гына түгел, Идегәйне данга күмәр өчен, "Борынгы Монголиядән башлап, Урта Азия белән дәвам итеп, Урта һәм Түбән Иделгә кадәр бөтен төрки-монгол дөньясындагы" батырлар галереясен тудыра [Урманче Ф., с. 61].

Субра карт Идегәй портретында зифа буй һәм чибәрлек, пәйгамбәр йөзле булу, кыюлык һәм батырлык белән беррәттән, чичән-импровизаторга хас зирәклек һәм күрәзәчелек сыйфатларын да ассызыклый. Субра картның күрәзәлеге, Ф. Урманче фикеренчә, стиле ягыннан дастанның гомуми эпик стиленнән аерылып тормый һәм тулысынча диярлек төрки героик эпос традицияләренә нигезләнә [Урманче Ф., с. 64].

Җырчы-импровизатор образының Н. Исәнбәтнең "Идегәй" (1941) трагедиясе герое Туктамыш теле белән әйттерелгән сыйфатлары да игътибарга лаек: «Кем соң ул? Шагыйрь! Әнә ул килә. Нинди куәт бар соң аның кулында? Тел. Шагыйрьнең тавышы көчле. Моннан кычкырса, Әстерханга ишетелә. Мин аларны үз гомеремдә бик күп күрдем. Алар безне урынлы да, урынсыз мактыйлар. Шуның каршына зур бүләкләр өмет итәләр. Шулай да шагыйрь вакытлы кычкыра белсә генә яхшы. Вакытсыз кычкырган әтәчне суеп ашыйлар» [Исәнбәт, Әсәрләр, II т. б. 119]. Трагедиядә Субра карт Туктамышны хан атларында каршы алырга һәм сәламләргә мәҗбүр итә. Хан моңа кадәр үзенә таныш булган импровизатор шагыйрьләрнең болай кыланырга җөрьәт итмәве турында әйтә.

Чичән образы Н. Исәнбәтнең «Җирән чичән белән Карачәч сылу» комедиясендә төп герой булып китә (1942) [Исәнбәт, Әсәрләр, III т., б. 261 – 352]. «Җирән чичән һәм Карачәч сылуның бу табышмаклы сүз һәм эшләре турында бездә һәм башка төрки халыкларда сакланган риваятьләр күп, язып басылганнары да бар. Җирән чичән – Идел буенда, Сарайда XIV гасырда яшәгән кеше», – дип яза 1967 елда Н. Исәнбәт [Исәнбәт, Татар халык табышмаклары, б. 31]. Табышмаклар китабына җыючысы һәм төзүчесе тарафыннан Җирән чичән исеменә бәйле «Сәрвиназ», «Айбикә», «Ачы булса да татлы ни? Татлы булса да ачы ни?», «Кемнең үлүе нәрсәгә тиң» кебек табышмак-әкиятләр, табышмак-мәзәкләр кертелгәннәр [Исәнбәт, Татар халык табышмаклары, б. 439 – 444, б. 450 – 456]. Н. Ханзафаров фикеренчә, «мондый табышмакларның, әкиятләрнең бик күбесен иҗади файдаланып, Н. Исәнбәт сюжетлы, мавыктыргыч сәхнә әсәре иҗат итүгә ирешкән». «Торыр җире дә булмаган Җирән

чичән үзенең зирәк акылы белән ханны хәйран калдыра. Ул Янгура бинең киемнәрен, акчасын отып, мәһәр бирә, өйләнү чыгымнарын түли, хәтта би киемнәрен киеп, аның улын кыйнап кайтара» [Ханзафаров, б. 89].

«Җирән чичән Токмач шәһәрен ота, илләр арасындагы бәхәс тынычлык белән хәл ителә. Җирән чичәннең ил алдындагы хезмәтен тану аның кешелек, шәхси хокукларын тану белән бергә туа». «Чичән үзен бәхетле саный, чөнки бөтен энҗе-мәрҗәннәрдән дә кыйммәтрәк иреге бар, чөнки аның «хак казнасыннан кыйммәтрәк» сөеклесе бар». «Биредә халыкчан характерларның төп сыйфатлары – акыл культына табыну, патриотлык, шәхси ирек сөю, горурлык дип әйтә алабыз» [Ханзафаров, б. 90].

Тутыя исемле кыз пьесада импровизатор шагыйрь Казанбаш Җирәненең җәмгыятьтәге урынын болай дип тасвирлый: «Тел остасы – чичән! Аның бер телен ишетү өчен генә дә, мәйданнан мәйданга ат җибәреп кенә алдыралар иде» [Исәнбәт, Җирән чичән..., б. 264]. Тудык җиңги аның нәрсә белән шөгыльләнүен җентекләп тасвирлый: «Әстерхан ягында, ди. Думбра чиртеп, акын булып, казакъ арасында йөри, ди» » [Исәнбәт, Җирән чичән..., б. 265].

Мәйданда дан алган Карачәч тә аңа туры килеп тора: «чичән кыз» [Исәнбәт, Җирән чичән..., б. 265]. Бу кыз образы аша драматург «зирәк, сөйкемле, турылыклы хатын-кыз турындагы идеалны гәүдәләндерә». [Ханзафаров, б. 87].

Чичән образы Н. Исәнбәтнең балалар өчен язылган «Бәрәзә песие Мыраубай батыр маҗаралары» әкиятендә дә очрый [Исәнбәт, Мыраубай батыр., б. 5 – 115]. Әлеге әсәрдә тел остасы - хәйләкәр төлке:

Менә төлке мактый хәзер Мыраубайны,
Теле белән алмак була урап аны,
Мырау моны астан гына күзли сынап,
Шундый чичән, акыллымы бу, ди, чынлап?
[Исәнбәт, Мыраубай батыр, б. 51].

Икенче очракта халык чичәне ролен мөнәҗәтләрне оста итеп башкаручы Гөл әби башкара: «Хәммәдия» мөнәҗәт көйләп карый». [Исәнбәт, Мыраубай батыр, б. 98].

## Нәтиҗәләр

Чичәннәр һәм импровизатор шагыйрьләр белән Нәкый Исәнбәт фольклор экспедицияләре вакытында таныша. Халык авыз иҗаты әсәрләрен ул мәдрәсә шәкерте булганда, 10 яшендә җыя башлый. Нәкый Исәнбәт чичәннәр – чичәнлек сәнгате җәмгыятьнең рухи мәдәниятенең тардицион нигезләрен саклаучылар дигән фикердә тора, шуңа күрә үзенең фәнни хезмәтләрендә һәм әдәби әсәрләрендә чичәнлек традицияләренең күренекле вәкилләрен, аларның башкару осталыгын, аудитория белән аралашу үзенчәлекләрен, әсәрләренең поэтикасын мәңгеләштерергә омтыла. Сукыр Фәррахның язмышына уңай йогынты ясавы галимнең чичәнлек проблемасына җитди игътибары турында сөйли (җырау-импровизаторның биографиясе, репертуары, әсәрләренең эчтәлеге һәм проблематикасы, башкару осталыгы һәм үзенчәлекләре, текстларының поэтикасы. – *асс. М. Х.*). Бер төркем фәнни мәкаләләрендә галим чичәннәрнең нәфис сүз осталары гына булмыйча, һәр сүзендә халыкның зирәк акылы чагылыш тапкан трибун шагыйрьләр икәнлеген дә исбатлый. Фольклор экспедицияләренең кульязма мирасын һәм материалларын анализлап, Н. Исәнбәт тарихның зур бер аралыгында – Алтын Урда дәвереннән башлап, XX гасыр урталарына кадәр яшәгән чичәннәрнең исемнәрен барлый һәм мәңгеләштерә. Галим төрки чичәнлек тардицияләре үрнәкләре кергән фольклор җыентыкларын төзүче була, шулай ук төрки халыкларның эпик мирасының җыелма текстларын булдыра («Идегәй», «Идекәй белән Морадым»).

## Йомгаклар

1920 еллардан алып, 1970 елларга кадәр Н. Исәнбәт тарафыннан төрки халык җырчылары һәм музыкантлары (җыраулар, чичәннәр, сисәннәр, акыннар), шулай ук аларның иҗатлары турында мәгълүматларны системага салу буенча зур эш башкарыла. Галим фольклористика, төрки тел белеме һәм әдәбият гыйлеменең актуаль проблемаларын өйрәнүгә саллы өлешен кертә. Төрки халыкларның авыз иҗаты мәсьәләләрен өйрәнүгә багышланган бер генә җитди фәнни хезмәт тә аның гыйльми эшчәнлегенә мөрәҗәгать итмичә башкарылмый. Н. Исәнбәтнең төрки мәдәнияттә чичәнлек һәм импровизаторлык феноменын өйрәнүгә керткән өлешен игътибарсыз калдыру фәнни этика ноктасыннан җинаятькә тиң һәм моңа юл куярга ярамый.

**Әдәбият**

*Аминева З. Р.* Развитие традиций сэсэнов в юго-восточной территории Башкортостана на современном этапе // Вестник БГУ. Уфа, 2011. Т. 16. №3(I). С. 1052 – 1054.

*Бакиров М. Х.* Генезис и древнейшие формы общетюркской поэзии [Текст] : автореф. дис. … д-ра филол.наук / М. Х. Бакиров. Казань: КГУ, 1999. 96 с.

*Бурангулов М. А.* Завещание Сэсэна [Текст] / Мухаметша Бурангулов; на башк. яз. Уфа: Изд-во «Китап», 1995. 352 с.

*Воронцов М.* Народный поэт Башкирии // Народное творчество. 1939. №3 С. 46-48.

*Вәлиуллина Ф. М.* “Идегәй” дастанында милли-мифологик һәм дини мотивлар [Текст] / Ф. М. Валиуллина. Казан: Дом печати, 2007. 180 б.

*Газиев И. М.* Зарождение профессионализма в музыкальной культуре древних тюрков // Вестник Челябинского государственного педагогического университета. 2008. №12. С.179 – 194.

*Жирмунский В.М.* Среднеазиатские народные сказители: Традиции и творческая импровизация [Текст] / В. М. Жирмунский. М.: Наука, 1964. 13 с. (VII Международный конгресс антропологических и этнографических наук, Москва, авг. 1964 г.)

*Исәнбәт Н.* Әсәрләр 4 т. Т.2. Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. 416 б.

*Исәнбәт Н.* Әсәрләр 4 т. Т. 3. Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. 431 б.

Идегәй: татар халык дастаны: Н. Исәнбәт җыйнамасы // Совет әдәбияты. 1940. № 11. Б. 39 – 76 б.

*Исәнбәт Н.* Татар халык табышмаклары. Казан: Тат. кит. нәшр., 1970. 568 б.

*Исәнбәт Н.* Бер дәрвишнең юл дәфтәре. // Н. Исәнбәтнең шәхси архивы. Кулъязма. 79 б.

*Исәнбәт Н.* Минем язучы булуым һәм халык иҗатын өйрәнүем. // Н. Исәнбәтнең шәхси архивы. Кулъязма. Машинкада басылган. 1960. 5 б.

*Исәнбәт Н.* Мыраубай батыр. Казан: Тат. кит. нәшр., 1974. 208 б.

*Кашгари М.* Словарь тюркских наречий: (Диван лугат-ат тюрк, XI в.) [Текст] / первый перевод на рус. яз. Алматы: Дайк Пресс, 2006. 1300 с.

*Путилов Б.* Эпическое сказительство: Типология и этническая специфика. М.: ГРВЛ, 1997. 296 с.

*Радлов В. В.* Опыт словаря тюркских наречий. Т. 4 / [Соч.] В.В. Радлова. СПб.: тип. Имп. акад. наук, 1911. [2] с., 2230 стб.

Татар халык мәкальләре [Текст]: Т. 1. / җыючы һәм төзүче Н. Исәнбәт. Казан: Тат. кит. нәшр., 1959. 916 б.

*Сагеева Г. Х.* Традиционная терминология татарской музыкальной культуры: семантическая реконструкция [Текст]: автореф. дис. … канд. искусствоведения / Г. Х. Сагеева. Казань: ТГГПУ, 2007. 26 с.

*Султангареева Р.* Башкирская школа сказительства и современность // Ватандаш. Уфа. 2007. №6. С. 164-171.

Сүз табучы сукыр Фәррах әңгәмәләре : [Н. Исәнбәтнең «Фәррах җырлары турында» дигән мәкаләсе белән]. Уфа: «Башкнига» һәм Башнаркомпрос нәшере, 1928. 32 б.

Указ Президиума Верховного Совета Башкирской АССР Об установлении звания «Народный сэсэн Башкирской АССР» // Красная Башкирия. 1944. 19 апреля.

*Урманче Б.* Исәнбәтнең урыны // Казан утлары. 1969. №12. Б. 131 – 133.

*Урманче Ф.* Народный эпос «Идегей». Казан: Фән, 1999. 200 с.

Фәррәх Дәүләтшин // “Башҡорт сәсәндәре” йыйынтығында. Өфө: Башҡ. кит. нәшр., 1953.

*Хәбибуллин Ф.* Фәррах Дәүләтшин эзләре буйлап // Кызыл Таң. 2017. 19, 21 декабрь.

*Хәбибуллин Ф.* Алсалар да күземне, бирмәдем мин сүземне... (Башкортстанның халык чәчәне Фәррах Дәүләтшинның тууына 130 ел // Кызыл таң. 2017. 26, 28 гыйнварь.

*Хәбибуллин Ф.* Сукыр Фәррах // Мәдәни җомга. 2018. 18 май.

*Ярми Сәете (Исмәгыйлев)*. Истәлегем. // Әзәби Башкортостан. 1956. №3, март.

*Яруллин А.* Память о нём жива (К 120-летию со дня рождения народного поэта Башкортостана) // Юлдаш. 2006. 4 мая.

Йырҙар һәм бәйеттер: Орденлы халыҡ йырсыһы Фәррах йырҙары һәм бәйеттәре. Өфө: Башк. кит. нәшр.,1939. 112 б.

Сәсәндең кәңәштәре. Өфө: Башҡ. кит. нәшр, 1947. 63 б.

Сәсән тауышы. Өфө: Башҡ. кит. нәшр, 1967. 18 б.

# НАКИ ИСАНБЕТ ОБ ИСКУССТВЕ СКАЗИТЕЛЬСТВА[1]

**Милеуша Мухаметзяновна Хабутдинова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
mileuscha@mail.ru.

**Фануз Афгалович Хабибуллин**,
Редакция «Кызыл тан»,
Россия, 450001, г. Уфа, ул. 50-летия Октября, д. 13,
kiziltan90@mail.ru.

В статье систематизируются сведения о вкладе ученого-энциклопедиста, фольклориста, классика татарской литературы Наки Исанбета в осмысление сказительской традиции в тюркской культуре. Материалом для исследования послужили теоретические труды ученого, посвященные изучению фольклора тюркских народов, результаты фольклорных экспедиций, систематизированные в сборниках произведений устного народного творчества, а также художественные произведения писателя, где встречается образ певца-импровизатора. Характер анализируемого текста повлиял на используемый в работе метод исследования (культурно-исторический, семиотико-культурологический, сравнительно-сопоставительний и др). Доказано, что Н. Исанбет стремился в своих теоретических трудах по фольклору сформировать исчерпывающее представление о творчестве сэсэнов (чичән) и увековечил их образы в своем литературном творчестве. В 1920-е гг. экспериментальная работа ученого с Ф. Давлетшиным завершилась изданием сборника его произведений. Анализ современных работ, посвященных феномену сказительства в тюркской среде, свидетельствует о том, что вклад Наки Исанбета в изучение этой темы незаслуженно игнорируется современными исследователями.

**Ключевые слова**: Наки Исанбет, устное народное творчество, тюркские народы, татары, сэсэн (чичән), джырау (җырау).

[1] Материал о поэте-импровизаторе Фаррахе Давлетшине подготовлен Ф.А. Хабибуллиным.

DOI: 10.26907/2311-2042-2021-17-2-141-168

# NAKI ISANBET'S ARTICLE "ON THE WAYS TO THE TATAR MUSIC DEVELOPMENT" (1923) AS A SOURCE OF SCIENTIFIC COMMENTATION

**Yulduz Nakievna Isanbet[1],**
mileuscha@mail.ru.

This article presents a textual scientific commentary on Naki Isanbet's article "On the Ways to the Tatar Music Development", published under a pseudonym in Kazan in 1923. It was a tribute to the memory of his elder brother who went missing during the Civil War. Our study convincingly proves that Naki Isanbet's article has not lost its relevance today. The scientist correctly identified the key tendencies in the study of Tatar folk music and outlined the ways for the development of professional Tatar music.

**Key words**: Tatar music, Tatar folk song, Naki Isanbet, A. Eichenwald, S. Gabyashi, S. Saydashev.

## Introduction

The folk melodies of the Kazan Tatars, recorded and adapted for a symphony orchestra by Anton Eichenwald, were first performed on August 3, 1923 at an oriental music concert, held in the Red Army Palace (now the K. Tinchurin Theater). The concert program included Tatar songs "Kaz Kanaty" ("A Goose Wing"), "Okop kөe" ("A Trench Song"), "Salkyn chishmə" ("An Ice-cold Spring"), "Mөslimk" ("Muslima"), "Tugan silt" ("Our Motherland"), and "Gazizk baldyz" ("Gaziz's Sister-in-Law"). It was the first symphony concert of oriental music in the history of Tatar music. The performers of Tatar folk songs, Sara Sadykova, Khakima Chamaeva, and Yarulla Chamaev, took part in it (Fig. 1).

Among newspaper publications, devoted to the symphony concert of oriental music [K kontsertu dirizhera Eikhenval'da], [Simfonicheskii kontsert TatMuzo], [Tatar җyrlaryn muzykaga…], [V. G-n.], [Zenz], [Simski, 1923], [Simski, 1928], [Sh. G.], [U-v], [Eichenwald], N. Isanbet's article "On the Ways to the Tatar Music Development" ("Tatar Muzyksyn Eshləu Yulinda") stands apart. It was published, as was typical of all his journalistic materials of the 1920s, under the pseudonym Z. Zakir [Zakir] (see: Appendix 1). The young poet N. Isanbet visited Kazan on his way to Kharkov University. By this time, the main themes and trends of his work had already been determined. From an early age, he was interested in Tatar folk art. The concert of A. Eichenwald and new personal impressions provided him with additional information for thinking about the fate of Tatar music in the past and in the future.

## Materials and research methods

In the appendix to this article, N. Isanbet's work is given in the original language, since we encountered objective difficulties in translating it from Tatar into Russian. Certain imperfections of the text can be explained by the fact that this material was published without the consent of the author and without his proofreading, as the article was prepared for publication after the poet's departure from Kazan. Moreover, in his work N. Isanbet used the terms that have no equivalents in the Russian language. When quoting N. Isanbet, we were forced to resort to approximate paraphrasing or use a simplified literal translation. In some cases, variant meanings of the translated words are given in brackets in order to facilitate the understanding of the article. Some terms are always translated in the same way: "Kyr" – "song" (and only once, its context-based meaning is "folk vocal music"), "kөy" is translated as "koi", "muzykany eshləү" – as "the formation of music; composing music; musical creative works", "madəniləshterү" – as "professionalization; creating professional music". The word "моң" is used by N. Isanbet in two meanings:

[1] The author had passed away before she saw the final version of the accepted article, so M. M. Khabutdinova, an executive editor, has built the structure of her article in accordance with the requirements of the journal.

1) “a melody”, but not any melody, only the one possessing the quality described by the Tatar word “моң’ (that is, in this case, “моң” meaning “ozyn køy”, and the “melody”, respectively, meaning “a lingering song”, or “uzun kyui”); 2) a definition of a specific emotional and psychological state. In the latter case, due to the lack of a Russian equivalent, the word is given in the Tatar language (the interpretation of the word “моң” will be discussed in more detail later).

**Discussion**

N. Isanbet’s article was published after the first responses to the concert appeared. No doubt, the author had thought over more than once about what was said in the article. Surely, in A. Eichenwald’s work, he found answers to some questions that had tormented him, and it took time to look at these issues from a slightly different angle to formulate his point of view on the prospects for the development of Tatar music.

Since the fall of the Kazan Khanate in 1552, for four and a half centuries, the Tatar people actually had no chance even for the elementary development of their spiritual culture. Only literature struggled to maintain its positions. It was after the famous “Imperial Manifesto on the Improvement of the State Order” of October 17, 1905, which granted democratic rights and freedoms in Russia, that some forms of concert and theatrical activity, characteristic of European and Russian culture, began to gradually develop in the cities with the Tatar population. Theater companies, small musical groups and individual performers began to apply for citizenship and, albeit sometimes with great difficulty, got permission to perform in public. Amateur art entered the path of professionalism.

But if the emerging Tatar theater was rapidly developing its own repertoire (including translated works) created by Tatar playwrights, then music, in this respect, lagged far behind. The few, essentially amateur, works of Tatar authors were in short supply; therefore, it was folk music that formed the basis of Tatar performers’ musical repertoire. It was folk music in its pure form and in simple arrangements for singing with accompaniment, or music for individual instruments and ensembles. But even the elementary adaptation of folk tunes turned out to be a complicated task and not only at the initial stage of the professional music formation, as time has shown.

The Tatars did not have their own composers with the necessary professional qualification. They still had to be educated, to pass all the long stages of musical education from primary to higher levels. However, education alone, moreover crash courses, did not guarantee the creation of music that could be perceived precisely as nationally Tatar. What is more, no one clearly understood what was to be done to achieve this goal. All that remained was to somehow focus on the traditions of folk music, which so far had not been studied yet. Tatar musicians of that time, those who grew up on folk music and perceived it not with their mind, but with their soul, did not necessarily need scientific knowledge about it. However, it was necessary for composers of other nationalities who tried to work in the field of Tatar music and for future educators of both Tatar composers and performers, especially singers. To understand the specific features of Tatar music, they needed both time, which they did not always have, and certain efforts. Some of the authors of new works proceeded from well-known traditions, others preferred to ignore, not to notice them. Everyone acted to the best of their talent, knowledge, and responsibility and with different results.

Monophonic folk tunes and new authors’ melodies, spiritually connected to them, were hardly amenable to harmonization, associated with the introduction of polyphony into Tatar music, the process inevitable in striving for its Europeanization. Without polyphony, one could not expect the development of either opera, ballet, or other European academic genres, which the figures of Tatar culture dreamed of. In N. Isanbet’s opinion, A. Eichenwald came closest to an adequate polyphonic arrangement of Tatar tunes.

The article has two parts. The first of them is devoted to the issues related directly to the work of A. Eichenwald, the second is about the national originality of Tatar music and some issues of the further development of Tatar professional music.

Beginning the article with the assumption that “the recent Tatar symphony evening, conducted by the venerable composer A. Eichenwald, triggered new thoughts about Tatar music and its future in the minds of many music lovers, in particular,” and finishing the article with the words that it was time to seriously discuss the development of Tatar music, that “I especially want to hear the opinion of musical figures, who are accustomed to keeping their work away from newspaper and magazine pages,” N. Isanbet, nevertheless, apparently did not hope for a broad discussion of the issues he raised. Comparing different points of view, he discussed them himself.

Both positive and negative opinions about the current state and future of Tatar music, given by the author, were not generally accepted or expressed by someone publicly, but were formulated as possible ones by N. Isanbet himself. At the same time, N. Isanbet did not argue with his potential opponents who were critical of Tatar music (it is not accidental that the title of the article has the note "Instead of debates," but not, for example, "As a matter of discussion"), and did not reject their point of view as antagonistic, hostile, but usually analyzed what it was caused by. N. Isanbet believed, in a number of cases, there were real grounds for expressing opposing views.

The author of the article expressed confidence that the emergence of professional Tatar music in the near future was historically inevitable, although he stated that "until now, forecasts about the future of Tatar music have been extremely pessimistic". N. Isanbet connected the future progress of Tatar music with the progress of Tatar culture in general.

He wrote that, in contrast to pessimistic forecasts, "the belief that, as the economic and political growth of independent peoples increases and develops, their languages, literature, theater, and music, the music of the Tatar people, whose other branches of culture are gradually maturing, will also someday grow up and come of age. Because, if music is a part of art, then art itself is a branch of culture, which can grow and develop only if all its individual elements are healthy. Like other branches of Tatar culture, its art is forced to go forward only by being wound on a common historical axis (in a common historical team only)", thus, N. Isanbet pointed out the first two steps that had already been taken in this direction in music [Zakir].

He believed the first step to be the collection and musical notation of folk kyuis scattered in different areas (in the personal library of N. Isanbet himself there were notation editions of recordings by S. Rybakov, M. Sultanov, M. Berg, and publications of post-revolutionary literary-musical and youth societies from Kazan, Orenburg, and Ufa well-known to the Tatar intelligentsia of that time). The second step, from his point of view, was the work of the authoritative musician Sultan Gabyashi who was the author of a) new musical works, partially woven from Tatar motifs, b) kyuis for a number of stage works, c) adaptations of folk songs for choral singing, based on research into sound composition, time signature, and metrics.

N. Isanbet thought that the young musician Salikh Saydashev was also moving in this direction, as if anticipating subsequent events, since Saydashev, who had worked in the Tatar theater from the fall of 1922, had not yet created his own musical pieces and simply used folk melodies in his theatrical productions.

At the same time, N. Isanbet did not overestimate his contemporaries' merits and admitted that "all these steps towards the professionalization of Tatar music were insufficient, it was a half measure. Although they were based on the desire to fit Tatar music into scientific, creative forms in accordance with the musical canons common to other peoples, the thing that struck most was the unconvincingness of these steps and the helplessness of the methods employed. It might be due to the fact that our professionals were not sufficiently armed with theoretical and scientific knowledge" [Zakir]. Since N. Isanbet clearly spoke not only of the "two steps" he was considering, but also about "all these steps" ("lukin bu adymnarnyң həmməse də", not "lukin bu adymnar", or "lukin bu ike adym da"), here, he apparently made a generalized objective assessment of all the previous experiences of collecting and composing Tatar music.

In the pre-October period, Tatar folk music was collected, processed and published, except in the case of M. Sultanov, not by Tatars, but by musicians of other nationalities, which N. Isanbet considered to be historically justified, although these recordings and arrangements did not always correspond to the folk originals. He did not doubt they had every right to work in the field of Tatar music. "Since the musical cultures of different peoples, as well as specific branches of culture, are not separated from each other by strong barriers, there are many common ties between them; thus, when the music of each cultured nation enters a period of its intensive development, no evidence exists in history of its independent development. Therefore, if recognized figures of Italian music could work to lay the foundations of French music, then German composers could just as easily master Russian music and be of great use to it. Without a doubt, we, of all others, cannot sit on the sidelines and not follow this tradition. This would not surprise anyone in this country either" [Zakir], – he thought (however, he was slightly mistaken about the latter).

In our time, Tatar music lives independently and stands out of sight of Tatar intellectuals. But from the beginning of the 1920s, for about half a century, the public was keenly interested in introducing serious genres into Tatar music and in adequately performing the works of Tatar music, especially those in which a folk song was used as a

